Татарстан Республикасының Шәһәр төзелеше
**КОДЕКСЫ**

Әлеге Кодекс Татарстан Республикасы халкына яшәү өчен уңай шартлар тәэмин итү максатларында, торак урыннарына кешеләрне урнаштыру, шәһәр төзелешен планлаштыру, шәһәр һәм авыл торак пунктларын кору, төзекләндерү системасын булдыру, аларның инженерия, транспорт һәм социаль инфраструктураларын үстерү, табигатьтән нәтиҗәле файдалану, тарихи-мәдәни мирас объектларын саклап калу һәм әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала.

## I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

### 1 статья. Төп төшенчәләр

Әлеге Кодекста түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

шәһәр төзелеше эшчәнлеге (алга таба шулай ук - шәһәр төзелеше) - гражданнарның, җәмгыятьнең һәм дәүләтнең мәнфәгатьләрен исәпкә алып, шулай ук күрсәтелгән территорияләрнең һәм торак пунктларының милли, тарихи-мәдәни, экологик, табигый үзенчәлекләрен исәпкә алып, территорияләрнең һәм торак пунктларының үсешен шәһәр төзелеше ягыннан планлаштыру, җир кишәрлекләреннән файдалануның төрләрен билгеләү, күчемсез объектларны проектлау, төзү һәм реконструкцияләү өлкәсендә дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, физик һәм юридик затлар эшчәнлеге ул;

шәһәр төзелешен фаразлау - гамәлдәге тенденцияләрнең мөмкин булган нәтиҗәләрен, аларның эволюцияләрен, бу процесста сәяси-икътисадый (хуҗалык) һәм хокукый механизмнарның ролен бәяләү кысаларында һәм шәһәр төзелеше системаларын үзгәртеп коруның һәм үстерүнең мөмкин булган параметрларын һәм кирәкле юнәлешләрен, территорияләрне планлы оештыруның һәм коруның техник нормативларын (төзелеш нормаларын һәм кагыйдәләрен) билгеләү максатларында, дәүләтнең социаль-шәһәр төзелеше стандартлары нигезендә һәм шәһәр төзелеше системаларын мониторинглау белешмәләрен комплекслы анализлау нигезендә башкарылучы фәнни-тикшеренү эшчәнлеге ул;

шәһәр төзелешен планлаштыру - түбәндәгеләрне үз эченә алучы фәнни нигезләнгән концепцияләрне, программаларны һәм тәкъдимнәрне әзерләү ул:

Татарстан Республикасы территорияләреннән, аерым административ-территория берәмлекләреннән, шул исәптән торак пунктларыннан, хуҗалык итүче субъектлардан (предприятиеләрдән, оешмалардан) функциональ файдалану;

хуҗалык эшчәнлегенең һәм тирәлекне шәһәр төзелеше ягыннан үзгәртеп коруның регламентларын, шулай ук территорияләрне коруның һәм төзелеш ярдәмендә башкача үзләштерүнең параметрларын билгеләү;

җирләрнең шәһәр төзелеше өчен әһәмиятен, кишәрлекләрнең икътисадый инвестицион потенциалын һәм җәлеп итү дәрәҗәсен билгеләү;

республиканың инженерия, транспорт һәм социаль инфраструктураларын (торак пунктларын һәм торак пунктлары территорияләрен) оештыру;

тарихи-мәдәни һәм табигать мирасын саклау, әйләнә-тирә табигать мохитенең параметрларын сәламәтләндерү һәм кирәкле сыйфат дәрәҗәсендә тоту;

шәһәр төзелешен проектлау - территорияләрне планлаштыру һәм корылышларын күләм-пространство ягыннан оештыру һәм территорияләрне инженерия җайланмалары белән тәэмин итү өлкәсендә территорияләрне планлаштыруның һәм коруның, биналарны һәм корылмаларны төзүнең һәм реконструкцияләүнең, инженерия җайланмаларын барлыкка китерү системаларының техник нормалары һәм кагыйдәләре нигезендә фәнни-тикшеренү, эзләнү, проектлау һәм башка төрле эшчәнлекнең комплексы ул;

шәһәр төзелешен җайга салу - әлеге Кодекста билгеләнгән вәкаләтләрне түбәндәге юллар белән башкарганда шәһәр төзелеше өлкәсендә дәүләт идарәсе һәм җирле үзидарә органнары күрүче чаралар системасы ул:

җир кишәрлекләрен һәм башка төрле күчемсез объектларны куллануның регламентларын (параметрларның, төрләрнең, шулай ук гомуми сервитутларның һәм чикләүләрнең мөмкин булган үзгәрешләре җыелмасын) билгеләү;

шәһәр төзелеше эшчәнлеген (территорияләрне төзекләндерү һәм яшелләндерү буенча фаразлау һәм проектлау эшләрен, планлаштыру эшләрен, күчемсез объектларны төзегәндә һәм реконструкцияләгәндә төзелеш-монтаж эшләрен) башкаруга рөхсәтләр бирү;

шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектларының билгеләнгән рәвештәге шәһәр төзелеше паспортларын, милекчелек турындагы таныклыкларны, шәһәр төзелеше объектларын биләүчеләрнең һәм алардан файдаланучыларның хокукларын һәм бурычларын билгеләүче башка документларны бирү;

шәһәр төзелеше системаларының торышын һәм эшләвен, әйләнә-тирә табигать мохитенең сыйфатын, кайбер объектларның һәм аларның төркемнәренең корылышы торышын, инженерия җайланмаларын, территорияләрнең, биналарның һәм корылмаларның җиһазлануын һәм төзекләндерелүен даими мониторинглауны алып бару;

проектлау һәм төзү өчен инженерия эзләнүләрен күзәтеп торуны һәм эзләнүләрне башкару өчен рөхсәтләрне теркәүне һәм бирүне алып бару;

җир кишәрлекләрен һәм башка төрле күчемсез объектларны билгеләнгән регламентлар һәм төрләр нигезендә шәһәр төзелеше ягыннан күзәтеп торуны, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә күчемсез объектларны төзегәндә төзелеш регламентларының һәм нормативларының, оештыру һәм хокукый нормаларның үтәлешен архитектур-төзелеш ягыннан күзәтеп торуны алып бару;

шәһәр төзелеше документациясен дәүләт тарафыннан экспертизалау, шәһәр төзелеше эшчәнлеген һәм төзелеш эшчәнлеген лицензияләү, шәһәр төзелешендә продукцияне һәм хезмәт күрсәтүләрне сертификацияләү;

җир кишәрлекләрен һәм күчемсез объектларны, шул исәптән төзелеп бетмәгәннәрен дә, шулай ук күчемсез объектларны проектлау, төзү һәм реконструкцияләү өчен бирелгән рөхсәтләрне кадастр исәбенә алуны һәм теркәүне алып бару;

шәһәр төзелеше документациясе - территорияләрнең һәм торак пунктларының үсешен шәһәр төзелеше ягыннан планлаштыру турындагы һәм аларны кору турындагы документация ул;

зоналаштыру - территорияләрнең һәм торак пунктларының үсешен шәһәр төзелеше ягыннан планлаштырганда территорияне зоналарга бүлү ул, бу чакта билгеләнгән зоналарның шәһәр төзелеше ягыннан файдалану төрләрен һәм алардан файдалануны чикләүләрне билгеләргә;

шәһәр төзелешендә күчемсез объектлар (алга таба - күчемсез объектлар) - үзләренә карата шәһәр төзелеше эшчәнлеге башкарылучы һәм граждан законнары белән билгеләнгән объектлар ул;

инженерия, транспорт һәм социаль инфраструктуралар - корылмаларның һәм транспорт, элемтә, инженерия җайланмаларының, шулай ук торак пунктларының һәм алар арасындагы территорияләрнең тотрыклы үсешен һәм эшләвен тәэмин итүче социаль һәм мәдәни-көнкүреш хезмәте күрсәтү комплексы ул;

торак пунктлары арасындагы территорияләр - торак пунктларының чикләреннән читтә урнашкан территорияләр ул;

торак пунктларының һәм территорияләрнең тотрыклы үсеше - шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашырганда халык көн итүенең уңай шартларын шәһәр төзелеше чаралары белән тәэмин итү максатларында территорияләрнең һәм торак пунктларының үсеше, шул исәптән хуҗалык эшчәнлегенең һәм башка төрле эшчәнлекнең әйләнә-тирә табигать мохитенә зарарлы йогынтысын чикләү һәм аннан хәзерге, киләчәк буыннарның мәнфәгатьләрендә нәтиҗәле файдалану ул;

дәүләтнең шәһәр төзелеше нормативлары һәм кагыйдәләре - Татарстан Республикасының архитектура һәм шәһәр төзелеше органы тарафыннан әзерләнгән һәм расланган, шәһәр төзелеше эшчәнлегенең барлык төрләрен башкарганда үтәлеше мәҗбүри булган норматив-техник документлар ул;

хокукый зоналаштыру - шәһәр, авыл торак пунктларының һәм җирле үзидарәнең башка берәмлекләренең территорияләрен кору кагыйдәләрен

әзерләү һәм гамәлгә ашыру өлкәсендә дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге ул;

җирдән файдалану һәм шәһәр һәм авыл торак пунктларының, җирле үзидарәнең башка берәмлекләренең корылышы кагыйдәләре (шәһәр һәм авыл торак пунктларының һәм җирле үзидарәнең башка берәмлекләренең шәһәр төзелеше уставлары) (алга таба - корылыш кагыйдәләре) - шәһәр төзелеше регламентларын алып бару юлы белән күчемсез объектлардан файдалануны һәм аларны үзгәртүне җайга салучы дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының, җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары;

шәһәр төзелеше регламенты - шәһәр һәм авыл торак пунктларының, җирле үзидарәнең башка берәмлекләренең җир кишәрлекләреннән һәм башка төрле күчемсез объектлардан файдалануның корылыш кагыйдәләрендә билгеләгән параметрларының һәм төрләренең, шулай ук һәр зона чикләрендә шәһәр төзелеше эшчәнлеген башкарганда күчемсез объектларның мөмкин булган үзгәрешләренең җыелмасы ул;

шәһәр төзелешендә җир кишәрлекләрен һәм башка төрле күчемсез объектларны рөхсәтле куллану - шәһәр төзелеше нигезендә күчемсез объектлардан файдалану; күрсәтелгән объектлардан файдалануның законнар нигезендә билгеләнгән чикләүләре, шулай ук сервитутлар ул;

кызыл линияләр - кварталлар, микрорайоннар һәм планлаштыру структурасының башка элементлары территорияләрен шәһәр, авыл торак пунктларындагы урамнардан, үтеп йөрү урыннарыннан, мәйданнардан аерып тору чикләре ул;

корылышны җайга салу линияләре - биналарны, корылмаларны, төзелмәләрне кызыл линияләрдән яисә җир кишәрлеге чикләреннән чыгыбрак урнаштырганда билгеләнүче корылыш чикләре ул.

2 статья. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген хокукый җайга салу

1. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген хокукый җайга салу әлеге Кодекс, Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнар һәм башка төрле норматив хокукый актлар белән гамәлгә ашырыла.

2. Татарстан Республикасының Шәһәр төзелеше кодексында һәм Татарстан Республикасының башка төрле норматив хокукый актларында шәһәр төзелеше өлкәсендә Татарстан Республикасы территориясе үсешен планлаштыруга карата; шәһәр төзелеше эшчәнлеге өчен җирләрне куллану шартларына һәм тәртибенә карата; икътисадый, экологик, социаль, мәдәни һәм милли үсеш өлкәсендә республика сәясәтенең нигезләрен һәм республика программаларын әзерләүгә һәм гамәлгә ашыруга карата; энергетика системаларын, энергетика объектларын, транспорт, элемтә объектларын урнаштыруга карата; территорияләрне һәм торак пунктларын планлаштыруның һәм коруның шәһәр төзелеше өлкәсендәге стандартларын

әзерләүгә карата; шәһәр төзелешендә дәүләт картографик-геодезик фонд белешмәләрен куллануга карата; шулай ук тиешле бюджетлардан һәм үсеш фондларыннан акчалар бүлеп бирүне таләп итүче шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектларын билгеләүгә карата шәһәр төзелеше таләпләре билгеләнә.

3. Шәһәр төзелеше эшчәнлеге мәсьәләләре буенча дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары, җирле үзидарә органнары норматив хокукый карарлар кабул итәләр.

4. Әгәр халыкара шартнамәдә әлеге Кодекстагыга караганда башка төрлерәк кагыйдәләр билгеләнгән булса, ул чакта халыкара шартнамә кагыйдәләре кулланылалар.

3 статья. Шәһәр төзелеше өлкәсендә дәүләт, җәмгыять мәнфәгатьләре һәм хосусый мәнфәгатьләр

1. Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә дәүләт мәнфәгатьләре - торак пунктларының һәм алар арасындагы территорияләрнең тотрыклы үсеше өчен, инженерия һәм транспорт инфраструктураларының дәүләт системалары эшләсен өчен, табигый байлыкларны саклау, тарихи-мәдәни һәм табигый мирасның дәүләт объектларын саклау өчен кирәкле шартларны тәэмин итүдә Татарстан Республикасы мәнфәгатьләре ул. Әгәр шәһәр төзелеше эшчәнлеге дәүләт мәнфәгатьләренә каршы килсә, мондый эшчәнлек туктатылырга мөмкин.

2. Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җәмгыять мәнфәгатьләре - көн иткәндә уңай шартлар, хуҗалык һәм башка төрле эшчәнлек нәтиҗәсендә шәһәр төзелеше чараларының әйләнә-тирә табигать мохитенә зарарлы йогынтысын чикләүне, экологик вәзгыятьне яхшыртуны, шәһәр һәм авыл торак пунктларының, җирле үзидарәнең башка берәмлекләренең, алар тирәсендәге территорияләрнең инженерия, транспорт һәм социаль инфраструктуралары үсешен, тарихи-мәдәни һәм табигый мирас объектлары территорияләрен саклап калуны тәэмин итүдә шәһәр һәм авыл торак пунктлары халкының мәнфәгатьләре ул. Әгәр шәһәр төзелеше эшчәнлеге дәүләт мәнфәгатьләренә каршы килсә, мондый эшчәнлек туктатылырга мөмкин.

3. Шәһәр төзелеше өлкәсендә хосусый мәнфәгатьләр - гражданнарның һәм юридик затларның үзләренеке булган җир кишәрлекләрендә шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру белән бәйле мәнфәгатьләре ул. Әгәр гражданнарның һәм юридик затларның шәһәр төзелеше эшчәнлеге чиктәш җир кишәрлекләре һәм башка төрле күчемсез объектлар милекчеләренең, җир биләүчеләрнең, җирдән файдаланучыларның һәм аларны арендалаучыларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруга комачаулык итсә, мондый эшчәнлек чикләнергә мөмкин.

4. Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә дәүләт, җәмгыять һәм хосусый мәнфәгатьләр норматив хокукый актларның таләпләрен, дәүләтнең

шәһәр төзелеше өлкәсендәге нормативларын һәм кагыйдәләрен үтәү; көн итү өчен уңай шартларны тәэмин итү максатларында шәһәр төзелеше һәм проектлау документациясен реализацияләү юлы белән, шулай ук аларның үтәлешен тикшереп тору юлы белән тәэмин ителәләр.

Шәһәр төзелеше өлкәсендә дәүләт һәм җәмгыять мәнфәгатьләрен килештерү дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан тәэмин ителәләр.

5. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашырганда барлыкка килгән бәхәсләр үз компетенциясе чикләрендә дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, җирле үзидарә органнары, суд тарафыннан хәл ителәләр.

6. Күчемсез мөлкәтне булдыру, куллану, реконструкцияләү һәм теләсә ничек башкача үзгәртүләр расланылган шәһәр төзелеше документациясенә, дәүләтнең шәһәр төзелеше нормативларына һәм корылыш кагыйдәләренә туры килергә тиеш.

7. Шәһәр төзелешенең республика халкы мәнфәгатьләренә кагылышлы төп мәсьәләләре законнарда каралган тәртиптә республика референдумына йә җирле референдумнарга чыгарылырга мөмкин.

4 статья. Шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектлары

Татарстан Республикасы территориясе, Татарстан Республикасы территориясенең өлешләре, торак пунктларының территорияләре, торак пунктлары һәм җирле үзидарәнең башка берәмлекләре территорияләренең өлешләре; торак пунктлары чикләрендә һәм алар арасындагы территорияләрдә урнашкан күчемсез объектлар һәм аларның комплекслары, башка территория-мөлкәт һәм табигать-ландшафт комплекслары шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектлары булалар. Шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектлары өчен шәһәр төзелеше эшчәнлеге документациясе әзерләнә.

Шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектларының чикләре шәһәр төзелеше документациясен билгеләнгән тәртиптә әзерләү процессында билгеләнә.

Федераль милектәге, шул исәптән махсус җайга салынырга тиешле шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектлары федераль законнар белән билгеләнә.

5 статья. Татарстан Республикасы торак пунктларының типлары

1. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген башкарганда торак пунктларының үзенчәлекләре, шул исәптән халкының саны, күрсәтелгән торак пунктларының фәнни-җитештерү специализациясе, шулай ук торак пунктларының халыкны урнаштыру системасындагы (алга таба - урнаштыру системасы) һәм Татарстан Республикасының административ-территория корылышындагы әһәмияте исәпкә алынырга тиеш.

2. Татарстан Республикасының торак пунктлары шәһәр (республика буйсынуындагы шәһәрләр, шәһәрләр һәм поселоклар) һәм авыл (авыллар, салалар һәм башкалар) торак пунктларына бүленәләр.

3. Халык санына карап, шәһәр һәм авыл торак пунктлары түбәндәгеләргә бүленәләр:

бик эре шәһәрләр (халык саны 1 миллионнан алып 3 миллион кешегә кадәр);

эре шәһәрләр (халык саны 250 меңнән алып 1 миллион кешегә кадәр);

зур шәһәрләр (халык саны 100 меңнән алып 250 мең кешегә кадәр);

уртача шәһәрләр (халык саны 50 меңнән алып 100 мең кешегә кадәр);

кечкенә шәһәрләр һәм поселоклар (халык саны 50 мең кешегә кадәр);

эре авыл торак пунктлары (халык саны 5 мең кешедән дә күбрәк);

зур авыл торак пунктлары (халык саны 1 меңнән алып 5 мең кешегә кадәр);

уртача авыл торак пунктлары (халык саны 200дән алып 1 мең кешегә кадәр);

кечкенә авыл торак пунктлары (халык саны 200дән дә азрак кеше).

4. Халык саны вакытлыча яисә даими булмаган һәм икътисадның тиешле тармагында хезмәт итү әһәмиятендәге объект ролен үтәмәгән торак пунктлары (тимер юл будкалары, урманчылар, маякчылар йортлары, кыр ыстаннары һәм башка шундыйлар), шулай ук ялгыз торучы йортлар әлеге торак пунктларын административ, җитештерү яисә территориаль мөнәсәбәтләр белән бәйләүче дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары, җирле үзидарә органнары карамагында булалар.

5. Торак пунктларының типларына карап, шәһәр төзелеше документациясенең төре һәм эчтәлеге, аны әзерләү тәртибе, аны Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган норматив хокукый актлар нигезендә килештерү һәм раслау тәртибе билгеләнә.

6. Торак пунктларының җирләреннән файдалану шартларына һәм тәртибенә карата шәһәр төзелеше таләпләре әлеге Кодекс һәм аның нигезендә кабул ителүче законнар һәм башка төрле норматив хокукый актлар белән билгеләнәләр.

<u>6 статья.</u> Шәһәр төзелеше эшчәнлеген махсус җайга салу

1. Әгәр территориядән файдалануның махсус кагыйдәләрен кертмичә, шәһәр төзелеше өлкәсендә хосусый, җәмгыять яисә дәүләт мәнфәгатьләрен тәэмин итү мөмкин булмаса яисә кыенлашса, шәһәр төзелеше эшчәнлеге махсус җайга салынырга тиеш.

Махсус җайга салынырга тиешле шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектлары (алга таба - махсус җайга салуның шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектлары) республика һәм җирле әһәмияткә ия булырга мөмкин. Махсус җайга салынырга тиешле республика һәм җирле әһәмияткә ия шәһәр

төзелеше эшчәнлеге объектларына кертү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

2. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген территорияләрдә һәм торак пунктларында махсус җайга салу түбәндәге юллар белән гамәлгә ашырыла:

махсус республика һәм җирле стандартларны һәм дәүләтнең шәһәр төзелеше нормативларын һәм кагыйдәләрен кертү;

шәһәр төзелеше документациясен әзерләүнең, килештерүнең һәм раслауның махсус тәртибен кертү;

төзелеш өчен махсус рөхсәтләр бирү (әлеге Кодексның 63 статьясы).

3. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген махсус җайга салырга тиешле территорияләргә тарихи-мәдәни мирас объектлары территорияләре; махсус сакланылучы табигать территорияләре; ирекле икътисадый зоналар территорияләре; табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш вәзгыятьләрнең йогынтысы булырга мөмкин территорияләр; гадәттән тыш экологик вәзгыятьләрнең, экологик бәла-казаларнын территорияләре, депрессив районнарның территорияләре һәм башка төрле территорияләр кертеләләр.

4. Махсус җайга салуның шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектлары булган торак пунктларына түбәндәгеләр кертелергә мөмкин:

Казан шәһәре - Татарстан Республикасы башкаласы;

тарихи торак пунктлары, шулай ук территорияләрендә тарих һәм мәдәният ядкәрләре булган торак пунктлары;

тормыш эшчәнлегенең махсус режимы булган шәһәр һәм авыл торак пунктлары (хәрби шәһәрчекләр һәм башка ябык административ-территория берәмлекләре), дәүләт табигать тыюлыкларындагы, милли парклардагы, табигать паркларындагы торак пунктлары һәм башка шундыйлар);

радиоактив пычрану, сейсмик активлык аркасында экологик шартлары аеруча уңайсыз булган яисә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш вәзгыятьләр йогынтысы булырга мөмкин шәһәр һәм авыл торак пунктлары.

5. Махсус җайга салуның шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектлары булган территорияләргә һәм торак пунктларына кертү Татарстан Республикасы законнары белән гамәлгә ашырыла.

6. Махсус җайга салуның шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектлары чикләре административ-территория берәмлекләре чикләре белән туры килмәскә дә мөмкин һәм алар конкрет территория-мөлкәт яисә табигать-ландшафт комплексын шәһәр төзелеше ягыннан үзгәртеп кору максатлары һәм бурычлары белән законнар нигезендә билгеләнәләр.

## II бүлек. Гражданнарның тормыш эшчәнлегенең уңайлы тирәлегенә хокукларын тәэмин итү

### 7 статья. Гражданнарның тормыш эшчәнлегенең уңайлы тирәлегенә хокукы

1. Һәр граждан тормыш эшчәнлегенең уңайлы тирәлегенә хокуклы.

2. Гражданның мондый хокукын гамәлгә ашыруы түбәндәгеләрне күз алдында тота:

территорияләрнең һәм торак пунктларының үсешен шәһәр төзелеше ягыннан планлаштыру;

шәһәр төзелеше эшчәнлеген башкаруда гражданнарның һәм җәмәгать берләшмәләренең катнашуы;

юридик һәм физик затларның шәһәр төзелеше буенча ачык мәгълүмат ала алуы;

шәһәр төзелеше эшчәнлеген дәүләти нормалаштыру;

шәһәр төзелеше эшчәнлегенең кайбер төрләрен лицензияләү;

төзелеш материалларының кайбер төрләрен һәм төзелеш өлкәсендәге хезмәт күрсәтүләрнең кайбер төрләрен сертификацияләү;

шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыруны һәм шәһәр төзелеше турындагы законнарның үтәлешен дәүләт һәм җәмәгать тикшереп торуы;

шәһәр төзелеше турындагы законнарны бозу нәтиҗәсендә гражданнарга китерелгән һәм аның нәтиҗәсендә тормыш эшчәнлеге тирәлеге начараюга китергән зыянны административ тәртиптә компенсацияләү;

шәһәр төзелеше турындагы законнарны бозу нәтиҗәсендә гражданнарның сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә китерелгән зыянны түләттерү;

шәһәр төзелеше турындагы законнарны бозуда гаепле затларны җаваплылыкка тарту.

### 8 статья. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген башкарганда гражданнарның Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә яшәү урынын сайлап алу хокукын тәэмин итү

1. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген башкарганда гражданнарның яшәү урынын сайлап алу һәм тормыш эшчәнлегенең уңайлы тирәлеге буенча конституциячел хокукларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле шартлар шәһәр төзелеше өлкәсендәге дәүләт сәясәте нигезендә тәэмин ителергә тиеш.

2. Шәһәр һәм авыл торак пунктлары территорияләрендә шәһәр төзелеше документациясе, корылыш кагыйдәләре, дәүләтнең шәһәр төзелеше нормативлары һәм кагыйдәләре, экологик һәм санитария-гигиена таләпләре, янгын куркынычсызлыгы нормалары һәм кагыйдәләре нигезендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге гамәлгә ашырыла.

9 статья. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген башкарганда территорияләрнең һәм торак пунктларының иминлеге һәм аларны табигый, техноген характердагы гадәттән тыш вәзгыятьләр йогынтысыннан яклау таләпләрен тәэмин итү

1. Шәһәр төзелеше эшчәнлеге территорияләрнең һәм торак пунктларының иминлеге һәм аларны табигый, техноген характердагы гадәттән тыш вәзгыятьләр йогынтысыннан яклау таләпләрен үтәгән килеш башкарылырга тиеш.

2. Территорияләрнең һәм торак пунктларының иминлеге һәм аларны табигый, техноген характердагы гадәттән тыш вәзгыятьләр йогынтысыннан яклау кагыйдәләре Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган норматив хокукый актлар, шулай ук архитектура һәм шәһәр төзелеше органнарының, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау, санитария-эпидемиология күзәтчелеге, гражданнар оборонасы, гадәттән тыш вәзгыятьләрне кисәтү һәм бетерү, дәүләтнең янгыннан саклану хезмәте, җир ресурслары һәм җир эшләре буенча , җир асты байлыкларын, елга-суларны, атмосфера һавасын, туфракны саклау органнарының норматив-техник документлары белән, дәүләт тикшереп торуының һәм күзәтчелегенең башка органнарының норматив-техник документлары белән билгеләнәләр.

3. Шәһәр төзелеше документациясенең барлык төрләренә территорияләрне һәм торак пунктларын табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш вәзгыятьләрдән яклау турындагы бүлекләр кертеләләр, шулай ук гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш вәзгыятьләрне кисәтү гамәлләре билгеләнәләр.

4. Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш вәзгыятьләр йогынтысы булырга мөмкин территорияләр һәм торак пунктлары өчен территорияләрне һәм торак пунктларын алда күрсәтелгән йогынтылардан яклау буенча махсус схемалар һәм проектлар әлеге статьяның 2 пунктында каралган таләпләр нигезендә әзерләнәләр.

5. Комплекслы тиешле инженерия эзләнүләренең материалларын исәпкә алмыйча, шәһәр төзелеше документациясен әзерләү, килештерү, раслау һәм гамәлгә ашыру тыела.

6. Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш вәзгыятьләр йогынтысы булырга мөмкин территорияләрдә һәм торак пунктларында тормыш эшчәнлеге тирәлегенең торышын мониторинглау алып барыла. Күрсәтелгән вәзгыятьләр турындагы белешмәләр дәүләтнең шәһәр төзелеше кадастрына кертеләләр.

10 статья. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген башкарганда әйләнә-тирә табигать мохитен саклау, экологик иминлек таләпләрен һәм санитар кагыйдәләрне тәэмин итү

1. Шәһәр төзелеше документациясен әзерләү, шәһәр һәм авыл торак пунктларын, биналарны, корылмаларны һәм төзелмәләрне төзү һәм реконструкцияләү, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау, экологик иминлек таләпләрен һәм санитар кагыйдәләрне үтәгән килеш, шәһәр һәм авыл торак пунктлары территорияләренең торышын, экологик иминлек өлкәсендәге табигатьне саклауның һәм табигатьтән файдалануның комплекслы территория схемаларын исәпкә алып билгеләнгән чикләүләрне, шулай ук әйләнә-тирә табигать мохитенә һәм кеше сәламәтлегенә хуҗалык эшчәнлегенең һәм башка төрле эшчәнлекнең зарарлы йогынтысы нәтиҗәләрен исәпкә алып башкарылырга тиеш.

Шәһәр төзелеше документациясен әзерләгәндә әйләнә-тирә табигать мохитен саклау буенча шәһәр төзелеше документациясен әзерләү заданиесендә билгеләнгән гамәлләр күз алдында тотылырга тиеш.

2. Шәһәр төзелеше документациясенең барлык төрләренә дә аны әзерләү заданиесе нигезендә җир асты байлыкларын, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау турындагы, табигый байлыклар һәм җир эшләре турындагы бүлекләр кертеләләр.

Татарстан Республикасы территориясенең гадәттән тыш экологик вәзгыять һәм экологик бәла-каза зоналары, территория-җитештерү комплекслары, шәһәрләр - эре сәнәгать үзәкләре һәм кайбер сәнәгать комплекслары өчен табигатьне саклауның һәм табигатьтән файдалануның комплекслы территория схемалары әзерләнәләр.

3. Җир кишәрлекләренец һәм башка төрле күчемсез объектларның милекчеләре, аларны биләүчеләр, алардан файдаланучылар һәм аларны арендалаучылар шәһәр төзелеше эшчәнлеген башкарганда әйләнә-тирә табигать мохитен саклау һәм экологик иминлек буенча шәһәр төзелеше документациясендә каралган таләпләрне, шулай ук санитар кагыйдәләрне үтәргә тиеш.

4. Химик һәм биологик матдәләр белән, зарарлы микроорганизмнар белән мөмкин булган концентрацияләрдән артыграк, радиоактив матдәләр белән мөмкин булган дәрәҗәләрдән артыграк микъдарларда зарарланган территорияләрдә халыкның яшәве, хуҗалык эшчәнлеген һәм башка төрле эшчәнлекне башкару кеше сәламәтлегенә зыян китерсә, мондый территорияләр әйләнә-тирә табигать мохитен саклау турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә консервацияләнергә һәм махсус эшкәртелергә тиеш.

Пычрану дәрәҗәсенә һәм күрсәтелгән территорияләрне сәламәтләндерү ысулына карап, алардан файдалануның махсус режимы кертелергә яисә эшләүнең башка төрле рәвеше билгеләнергә мөмкин.

5. Әгәр дәүләт яисә җәмгыять мәнфәгатьләре экологик яктан уңайсыз булган территорияләрдә дә хуҗалык эшчәнлеген һәм башка төрле эшчәнлекне башкаруны таләп итсә, мондый территорияләрдә халыкның вакытлыча яшәве рөхсәт ителә, әмма шәһәр төзелеше документациясе нигезендә шәһәр төзелеше эшчәнлеген махсус җайга салу билгеләнергә тиеш (әлеге Кодексның 6 статьясы).

11 статья. Предприятиеләрне, учреждениеләрне, оешмаларны урнаштыруны һәм рекреацион әһәмияткә, сәламәтләндерү әһәмиятенә ия булган объектларны урнаштыруны тәэмин итү

1. Предприятиеләрне, учреждениеләрне, оешмаларны урнаштыру дәүләт шәһәр төзелеше нормативларына һәм кагыйдәләренә, территорияләрне зоналаштыру таләпләренә, халыкның көн итүе өчен уңай шартлар тәэмин итү таләпләренә туры килергә тиеш.

2. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген башкарганда гражданнарның ялга булган хокукларын тәэмин итү максатларында уңайлы табигый-климатик, дәвалау, санитария-гигиена шартлары һәм башка төрле уңай шартлар исәпкә алынырга тиеш.

3. Халыкның даими яшәү урыннарында шәһәр төзелеше документациясе, дәүләтнең шәһәр төзелеше нормативлары һәм кагыйдәләре нигезендә рекреацион әһәмияткә, сәламәтләндерү әһәмиятенә ия булган объектларны урнаштыруны тәэмин итү өчен территорияләр бүлеп бирелә.

4. Предприятиеләрне, учреждениеләрне, оешмаларны һәм рекреацион, сәламәтләндерү әһәмиятенә ия булган объектларны урнаштыруны Татарстан Республикасының дәүләт идарәсе органнары һәм җирле үзидарә органнары үз компетенцияләре чикләрендә тәэмин итәләр.

12 статья. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген башкарганда тарихи-мәдәни мирас объектларын һәм махсус саклanылучы табигать территорияләрен саклап калу таләпләрен үтәүне тәэмин итү

1. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген башкарганда тарихи-мәдәни мирас объектларын һәм махсус саклanылучы табигать территорияләрен саклап калу таләпләрен үтәү тәэмин ителергә тиеш.

2. Тарихи һәм мәдәни ядкярләре булган, шул исәптән археология ядкярләре, махсус саклanылучы табигать территорияләре булган торак пунктларында һәм территорияләрдә саклау зоналарының чикләре билгеләнә, аларның кысаларында тарихи-мәдәни мирас объектларына, махсус саклanылучы табигать территорияләренә, әйләнә-тирә табигать мохитенә зыян китерүче яисә аларның торышын начарайтучы һәм аларның

бөтенлеген, сакланышын бозучы шәһәр төзелеше эшчәнлеге, хуҗалык эшчәнлеге һәм башка төрле эшчәнлек тыела яисә чикләнә.

Тарихи һәм мәдәни ядкярләрне саклау зоналарының чикләре, махсус сакланылучы табигать территорияләренең чикләре шәһәр төзелеше документациясендә билгеләнәләр һәм тарихи һәм мәдәни ядкярләрне саклау турындагы, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә расланалар.

13 статья. Халыкка социаль һәм мәдәни-көнкүреш хезмәте күрсәтү объектларын урнаштырганда шәһәр төзелеше таләпләрен үтәүне тәэмин итү

1. Территорияләрнең һәм торак пунктларының үсешен шәһәр төзелеше ягыннан планлаштыру турында һәм аларны кору турында шәһәр төзелеше документациясендә тормыш эшчәнлеген тәэмин итүнең республикада билгеләнгән социаль-шәһәр төзелеше стандартлары нигезендә халыкка социаль һәм мәдәни-көнкүреш хезмәте күрсәтү объектларының составы һәм структурасы, корылышның комплекслылыгын, төрле социаль-демографик һәм һөнәри төркемнәрнең мәнфәгатьләрен исәпкә алып, билгеләнә.

2. Татарстан Республикасының дәүләт идарәсе органнары, җирле үзидарә органнары шәһәр һәм авыл торак пунктларында торак пунктларының планлаштыру структурасы, аларның торакара социаль һәм мәдәни-көнкүреш хезмәте күрсәтү әһәмияте нигезендә һәм, эшкуарлык үсешен, хезмәт күрсәтү өлкәсендә конкуренцияне исәпкә алып, социаль һәм мәдәни-көнкүреш хезмәт күрсәтү системасын тәшкил итәләр.

3. Халыкка социаль һәм мәдәни-көнкүреш хезмәте күрсәтү объектларының билгеләнешен үзгәртү халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү дәрәҗәсенең шәһәр төзелеше буенча дәүләт нормативлары һәм кагыйдәләре билгеләгән дәрәҗәдән кимемәскә тиеш.

14 статья. Территорияләрнең инженерия инфраструктурасы һәм аларны төзекләндерү системаларын булдыруны тәэмин итү

1. Халыкның яшәеше һәм хуҗалык эшчәнлеге, башка төрле эшчәнлек башкару өчен файдаланылучы территорияләрдә, торак пунктының тибын һәм аның корылышын, хуҗалык эшчәнлегенең һәм башка төрле эшчәнлекнең төрен исәпкә алып, дәүләтнең шәһәр төзелеше нормативлары, кагыйдәләре һәм стандартлары нигезендә территорияләрнең инженерия инфраструктурасы һәм аларны төзекләндерү (территорияләрне яшелләндерү һәм инженерия ягыннан әзерләү) системалары төзелә.

Территорияләрнең инженерия инфраструктурасы һәм аларны төзекләндерү системасының төрләре һәм алардан файдалануны һәм эксплуатацияләрне чикләүләрнең төрләре шәһәр төзелеше эшчәнлеген

башкарганда шәһәр төзелеше документациясе нигезендә һәм аның нигезендә әзерләнүче махсус схемалар һәм территорияләрнең инженерия инфраструктурасы һәм аларны төзекләндерү проектлары нигезендә билгеләнәләр.

2. Шәһәр төзелеше документациясен әзерләгәндә, магистраль челтәрләрне һәм инженерия инфраструктурасының төп корылмаларын төзегәндә һәм эксплуатацияләгәндә, шулай ук территорияләрне инженерия әзерләү эшләрен башкарганда су белән тәэмин итү чыганакларын, туфракны, атмосфера һавасын пычранудан, яшел фонд объектларын пычранудан һәм юкка чыгарудан саклап калу, шул исәптән территорияләрдәге инженерия җиһазлау һәм территорияләрне төзекләндерү корылмаларының һәм коммуникацияләренең (канализациянең чистарткыч корылмалары, җылылык, электр һәм газ тәэминаты объектлары, көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларының чүплекләре, чүп эшкәртү заводлары һәм башкалар) зарарлы йогынтысыннан саклап калу максатларында шушы территорияләр тирәсенә урнашкан торак пунктларының мәнфәгатьләре исәпкә алыналар.

3. Татарстан Республикасы территорияләренең, шәһәр һәм авыл торак пунктларының һәм җирле үзидарәнең башка берәмлекләренең инженерия инфраструктурасын һәм аларны төзекләндерү системаларын булдыру һәм үстерү Татарстан Республикасының дәүләт идарәсе органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан тәэмин ителә.

4. Торак пунктлары территорияләренең инженерия инфраструктурасы һәм аларны төзекләндерү системалары үсеше территорияләрнең инженерия инфраструктурасы һәм аларны төзекләндерү системалары үсеше белән бәйле булырга тиеш һәм торак пунктларының, алар арасындагы территорияләрнең тотрыклы үсеше тәэмин ителергә тиеш.

5. Күчемсез объектлар милекчеләренең, аларны биләүчеләрнең, алардан файдаланучыларның һәм аларны арендалаучыларының торак пунктлары территорияләренең инженерия инфраструктурасы һәм аларны төзекләндерү системаларын үстерүне һәм эксплуатацияләүне тәэмин итүдә катнашулары, Татарстан Республикасының дәүләт идарәсе органнары һәм җирле үзидарә органнары белән килешүләр буенча законнар нигезендә башкарылалар.

## <u>15 статья.</u> Эш һәм ял урыннарына, социаль-мәдәни хезмәт күрсәтү үзәкләренә керә алу шартларын булдыру

1. Эш һәм ял урыннарына, социаль-мәдәни хезмәт күрсәтү үзәкләренә керә алу шартларын халыкның барлык категорияләре өчен, шул исәптән, яшәү урыннарына карамастан, инвалидлар өчен булдыру максатларында шәһәр һәм авыл торак пунктлары территорияләре транспорт корылмалары һәм коммуникацияләре белән тәэмин ителәләр.

Транспорт инфраструктурасының дәүләт һәм җирле системалары, транспорт төрләре үсеше дәүләт төзелеше документациясендә һәм аның нигезендә әзерләнүче махсус схемалар һәм транспорт инфраструктурасы үсеше проектлары нигезендә билгеләнә.

2. Торак пунктын проектлаганда һәм төзегәндә торак пункты һәм аның табигый зонасының барлык өлешләре белән, шулай ук башка территорияләр һәм торак пунктлары белән уңайлы һәм имин элемтәләр тәэмин итү максатларында, торак пунктын һәм аның тирәсендәге территорияне структур планлаштыру белән бәйле транспорт һәм урам-юл челтәре коммуникацияләренең бердәм системасын күз алдында тоту кирәк.

3. Татарстан Республикасының транспорт инфраструктурасы системасын һәм транспорт инфраструктурасының җирле системасын булдыруны һәм үстерүне Татарстан Республикасының дәүләт идарәсе органнары һәм җирле үзидарә органнары тәэмин итә.

4. Күчемсез объектлар милекчеләренең, аларны биләүчеләрнең, алардан файдаланучыларның һәм аларны арендалаучыларның торак пунктлары транспорт инфраструктурасының һәм алар тирәсендәге территорияләрнең транспорт инфраструктурасының системаларын Татарстан Республикасының дәүләт идарәсе органнары һәм җирле үзидарә органнары белән килешүләр буенча үстерүне һәм эксплуатацияләүне тәэмин итүдә катнашу законнар нигезендә башкарыла.

## 16 статья. Гражданнарның һәм юридик затларның җир кишәрлекләреннән файдалануларына карата шәһәр төзелеше таләпләренең үтәлешен тәэмин итү

Шәһәр төзелеше эшчәнлеген башкарганда җир кишәрлекләренең милекчеләре, аларны биләүчеләр, алардан файдаланучылар һәм аларны арендалаучылар булган гражданнарның һәм юридик затларның шушы җир кишәрлекләреннән файдаланулары корылыш кагыйдәләрендә каралган шәһәр төзелеше регламентлары нигезендә күчемсез объектлардан рөхсәтле файдалануны, шулай ук проект-планлаштыру документациясендә билгеләнгән кызыл сызыкларны үтәгән килеш башкарыла.

## 17 статья. Инвалидларның инженерия, транспорт һәм социаль инфраструктуралар объектларына каршылыксыз кереп йөрү шартларын тудыру

1. Татарстан Республикасының дәүләт идарә органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар инвалидларның (шул исәптән кресло-коляскадан һәм озатып йөрүче этләрдән файдаланучы инвалидларның) социаль инфраструктура объектларына (торак, җәмәгатьчелек һәм җитештерү биналарына, корылмаларына һәм төзелмәләренә, спорт

корылмаларына, ял урыннарына, мәдәни-тамаша һәм башка төрле учреждениеләргә) каршылыксыз кереп йөрүләре өчен, шулай ук һава, тимер юл, автомобиль, су транспортыннан һәм шәһәр, шәһәр яны пассажир транспортының барлык төрләреннән, элемтә һәм мәгълүмат чараларыннан каршылыксыз файдаланулары өчен шартлар тудырырга тиеш.

2. Шәһәр һәм авыл торак пунктларын шәһәр төзелеше ягыннан планлаштыру һәм кору, биналарны, корылмаларны һәм төзелмәләрне, аларның комплексларын, инженерия һәм транспорт инфраструктуралары объектларын инвалидларның инженерия, транспорт һәм социаль инфраструктуралар объектларына каршылыксыз кереп йөрүләре һәм мондый объектлардан файдаланулары өчен шартлар тудырмыйча гына төзү һәм реконструкцияләү максатларында проектлау документациясен әзерләү рөхсәт ителми.

Инвалидларның инженерия, транспорт һәм социаль инфраструктуралар объектларына каршылыксыз кереп йөрүләре һәм мондый объектлардан файдаланулары өчен шушы объектларны яраклаштыру гамәлләре федераль, республика һәм җирле максатчыл программалар нигезендә башкарыла.

Әгәр гомуми кулланылыштагы инженерия, транспорт һәм социаль инфраструктуралар объектларын инвалидлар каршылыксыз кереп йөрү өчен яраклаштыру мөмкин булмаса, мондый объектларның милекчеләре, инвалидларның җәмәгать берләшмәләре белән килешеп, аларның минималь ихтыяҗларын тәэмин итәрлек гамәлләр башкарырга тиеш.

3. Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнары һәм җирле үзидарә органнары, оешмалар инвалидларның мәнфәгатьләренә кагылышлы мәсьәләләрнең карарларын әзерләү өчен инвалидларның җәмәгать берләшмәләренең вәкаләтле вәкилләрен җәлеп итәләр. Мондый мәсьәләләр буенча инвалидларның җәмәгать берләшмәләренең вәкаләтле вәкилләре катнашыннан башка гына кабул ителгән карарлары суд тарафыннан гамәлгә яраксыз дип танылырга мөмкин.

<u>18 статья.</u> Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә фикер алышуларда һәм карарлар кабул иткәндә гражданнарның, аларның берләшмәләренең һәм юридик затларның катнашуы

1. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм юридик затлар яшәү урыны буенча тормыш эшчәнлеге мохитенең торышы турында, аның күздә тотылучы үзгәрешләре турында (граждани торак объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә, территорияләрне төзекләндергәндә, инженерия һәм транспорт коммуникацияләре сузганда) дөрес, тулы һәм үз вакытында мәгълүмат алырга һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында бүтән төрле мәгълүмат алырга хокуклы, моңа закон нигезендә дәүләт сере дип танылган мәгълүмат керми.

2. Гражданнарга, аларның берләшмәләренә һәм юридик затларга шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең тиешле органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан массакүләм мәгълүмат чаралары аша, иҗтимагый фикер алышулар уздыру, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә экспозицияләр һәм күргәзмәләр оештыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

3. Тормыш эшчәнлеге мохитенең торышы турында һәм аның күздә тотылучы үзгәрешләре турында мәгълүмат бирелмәгән, вакытында бирелмәгән, тулы һәм яисә дөрес мәгълүмат бирелмәгән очракта, Татарстан Республикасы гражданнары судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

4. Татарстан Республикасы гражданнары һәм аларның берләшмәләре, шәһәр төзелеше документациясе расланганчы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә теләсә нинди рәвештә (гражданнар җыелышларында (җыеннарында), җәмәгать тыңлауларында, шәһәр төзелеше документациясе буенча фикер алышуларда катнашу) фикер алышырга, тәкъдимнәр кертергә һәм карарлар әзерләүдә катнашырга, үзләренең тәкъдимнәрен карауны таләп итәргә хокуклы.

Татарстан Республикасы гражданнары һәм аларның берләшмәләре, шәһәр төзелеше документациясе расланганчы, үз акчалары исәбеннән шушы документациягә бәйсез экспертиза уздыра алалар. Мондый экспертизалар уздыру кызыксынучы оешмалар белән шәһәр төзелеше документациясен килештерү һәм шәһәр төзелеше документациясенә дәүләт экспертизасы уздыру вакытларын кичектермәскә тиеш. Шәһәр төзелеше документациясенә бәйсез экспертизалар шәһәр төзелеше һәм проектлау документациясенә дәүләт экспертизасы органнарының бәяләмәләренә карата судка яисә арбитраж судка шикаять белдерү өчен файдаланылырга мөмкин.

5. Дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, җирле үзидарә органнары үз компетенциясе чикләрендә һәм закон нигезендә гражданнарның һәм аларның берләшмәләренең мәнфәгатьләренә кагылышлы шәһәр төзелеше мәсьәләләре буенча аларның гаризаларын карыйлар һәм билгеләнгән вакытларда аларга дәлилле җаваплар тапшыралар.

6. Шәһәр төзелеше эшчәнлеге Татарстан Республикасы гражданнарының һәм аларның берләшмәләренең мәнфәгатьләренә кагылган очракларда, алар түбәндәгеләргә хокуклы булалар:

шәһәр төзелеше турындагы законнар бозылган очракта, объектларны урнаштыру, проектлау, төзү, реконструкцияләү яисә эксплуатациягә тапшыру турындагы карарларны юкка чыгаруны административ яисә суд тәртибендә таләп итәргә;

шәһәр төзелеше турындагы законнарны бозган килеш эксплуатацияләнүче предприятиеләрнең һәм башка объектларның

эшчәнлеген чикләүне, туктатып торуны яисә бөтенләй туктатуны административ яисә суд тәртибендә таләп итәргә;

шәһәр төзелеше һәм проектлау документациясенә дәүләт экспертизасы бәяләмәләренә карата судка шикаять белдерергә;

шәһәр төзелеше турындагы законнарны бозу аркасында гражданнарның сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә китерелгән зыяннны түләттерү турында судка дәгъва белән мөрәҗәгать итәргә;

шәһәр төзелеше турындагы законнарны бозуда гаепле гражданнарны законнарда каралган тәртиптә җаваплылыкка тартуны таләп итәргә.

19 статья. Шәһәр төзелеше өлкәсендә профессиональ-иҗади оешмалар (берләшмәләр)

Шәһәр төзелеше өлкәсендә профессиональ мәнфәгатьләрнең уртаклыгы нигезендә барлыкка килгән һәм законда билгеләнгән тәртиптә уставлары нигезендә теркәлгән профессиональ-иҗади оешмалар (берләшмәләр) түбәндәгеләргә хокуклы:

дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарына шәһәр төзелеше өлкәсендә законнар һәм башка норматив хокукый актлар әзерләү турында тәкъдимнәр кертергә;

шәһәр төзелеше өлкәсендәге законнарның һәм башка норматив хокукый актларның проектларын әзерләүдә катнашырга;

шәһәр төзелеше документациясен әзерләүдә, шәһәр төзелеше документациясенә дәүләт экспертизасын уздыруда катнашырга;

шәһәр төзелеше документациясен әзерләү буенча конкурслар уздыруда катнашырга;

күрсәтелгән профессиональ-иҗади оешмаларда (берләшмәләрдә) катнашучыларның һәм (яисә) әлеге Кодексның 18 статьясында каралган башка гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен чагылдырырга һәм якларга.

20 статья. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген башкарганда гражданнарның һәм юридик затларның бурычлары

Гражданнар һәм юридик затлар түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

тормыш эшчәнлеге мохитен сакларга;

шәһәр төзелеше документациясе, корылыш кагыйдәләре нигезендә шәһәр төзелеше эшчәнлеген башкарырга;

әйләнә-тирә табигать мохитенә, тарих һәм мәдәният ядкярләренә, табигать ядкярләренә, шәһәр, авыл һәм табигать ландшафтларына, инженерия, транспорт инфраструктуралары объектларына һәм территорияләрне төзекләндерүгә зарарлы йогынты ясый торган, өченче затларның законлы мәнфәгатьләренә кагыла торган һәм чиктәш җир

кишәрлекләренең, бүтән төрле күчемсез объектлар милекчеләренең, аларны биләүчеләрнең, аларны арендалаучыларның яисә алардан файдаланучыларның хокукларын гамәлгә ашыруга тоткарлык ясый торган эшләр башкармаска;

биналарны, төзелмәләрне һәм корылмаларны, бүтән төрле күчемсез объектларны тиешенчә тоту, җир кишәрлекләрен төзекләндерү эшләрен шәһәр төзелеше һәм проектлау документациясе, шәһәр төзелеше нормативлары һәм кагыйдәләре, экологик, санитар, янгынга каршы һәм башка махсус нормативлар нигезендә генә башкарырга;

шәһәр төзелеше өлкәсендә тикшереп торучы дәүләт органнары күрсәтмәләрен үтәргә;

шәһәр төзелеше өлкәсендә тикшереп торучы дәүләт органнарының урындагы затларына үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтергә;

күчемсез мөлкәт объектларына техник инвентаризация уздыручы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектларының дәүләт кадастрын һәм мониторингын алып баручы оешмаларга үзләренә караган күчемсез объектларның үзгәреше турында дөрес мәгълүматлар бирергә;

шәһәр төзелеше һәм проектлау документациясе күчермәләренең, шулай ук төзелеш өчен комплекслы инженерия эзләнүләре материаллары күчермәләренең берәр нөсхәсен тиешле архивларга һәм архитектура, шәһәр төзелеше органнары фондларына бушлай тапшырырга.

## III бүлек. Шәһәр төзелеше өлкәсендә дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының вәкаләтләре һәм җирле үзидарә эшчәнлеге предметлары

### 21 статья. Шәһәр төзелеше өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләре

Шәһәр төзелеше өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

шәһәр төзелеше эшчәнлеген законнар белән җайга салу;

шәһәр төзелеше өлкәсендә дәүләт сәясәтен билгеләү;

шәһәр төзелеше өлкәсендә мөһим республика программаларын раслау;

республикада яшәеш мохитенең дәүләт социаль-шәһәр төзелеше стандартларын кабул итү;

Татарстан Республикасының административ-территория корылышы мәсьәләләрен хәл итү;

шәһәр төзелеше өлкәсендәге законнарның үтәлешен тикшереп тору.

<u>22 статья.</u> Шәһәр төзелеше өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре

Шәһәр төзелеше өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

шәһәр төзелеше өлкәсендә закон проектлары әзерләү һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертү;

әлеге Кодекс һәм башка законнар нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларын әзерләү һәм кабул итү;

шәһәр төзелеше өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру;

шәһәр төзелеше өлкәсендә республика программаларын әзерләү һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы раславына кертү;

шәһәр төзелеше өлкәсендә мөһим республика программаларын, Татарстан Республикасы территориясенең үсешен шәһәр төзелеше ягыннан планлаштыру турында шәһәр төзелеше документациясен, шулай ук инженерия, транспорт һәм социаль инфраструктуралары үсешенең, республика территориясен төзекләндерүнең схемаларын һәм проектларын раслау һәм гамәлгә ашыру;

махсус җайга салынучы шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектлары өчен шәһәр төзелеше документациясен башкарма хакимиятнең федераль органнары белән берлектә килештерү һәм раслау тәртибен билгеләү;

Татарстан Республикасы мәнфәгатьләренә кагылышлы федераль шәһәр төзелеше документациясен килештерү;

шәһәрләрнең һәм торак пунктларның генераль планнарын, республика әһәмиятенә ия махсус җайга салынучы шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектлары булган территорияләрнең үсешен шәһәр төзелеше ягыннан планлаштыру турындагы шәһәр төзелеше документациясен раслау;

федераль әһәмияткә ия объектлардан гайре, махсус җайга салынучы шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектларының чикләрен, шушы территорияләрдә шәһәр төзелеше эшчәнлеген махсус җайга салу тәртибен билгеләү;

шәһәр, авыл һәм җирле үзидарәнең башка берәмлекләренең чикләре проектларын раслау;

шәһәр яны зоналарының чикләрен һәм режимнарын раслау;

Татарстан Республикасында күчемсез объектларны төзүгә һәм территория-мөлкәт комплексларын үзгәртеп коруга рөхсәтләр бирү тәртибен билгеләү;

республика әһәмиятенә ия күчемсез объектларны, шулай ук республика бюджеты акчаларын җәлеп итү юлы белән төзелүче объектларны төзү турында, аларны төзүгә һәм реконструкцияләүгә рөхсәтләр алу өчен документлар әзерләү турында карарлар кабул итү;

шәһәр төзелеше өлкәсендәге законнарның һәм бүтән норматив хокукый актларның үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

шәһәр төзелеше өлкәсендәге бәхәсләрне үз компетенциясе чикләрендә хәл итү;

Татарстан Республикасы милкендә булган җирләрдән бүлеп алынган җир кишәрлекләрендә шәһәр һәм авыл торак пунктларының ихтыяҗын тәэмин итү турында карарлар кабул итү;

Татарстан Республикасының архитектура һәм шәһәр төзелеше органының структурасын һәм аның турындагы нигезләмәне раслау;

шәһәр төзелеше өлкәсендә кабул ителүче һәм кабул ителгән карарлар турында Татарстан Республикасы халкына җиткерү;

шәһәр төзелеше өлкәсендә хөкүмәтара шартнамәләр төзү;

шәһәр төзелеше турындагы законнарны бозган очракларда, район һәм республика буйсынуындагы шәһәр администрациясе башлыкларының карарларын һәм күрсәтмәләрен гамәлдә булуын туктатып тору, министрлыкларның, дәүләт комитетларының һәм Министрлар Кабинетына буйсынучы башка органнарның актларын юкка чыгару;

Татарстан Республикасы территорияләренең үсешен шәһәр төзелеше ягыннан планлаштыру турындагы шәһәр төзелеше документациясен, программалар әзерләүне, шәһәр төзелеше өлкәсендә фәнни-тикшеренү эшләре уздыруны, Татарстан Республикасы законнарының һәм бүтән норматив хокукый актларының проектларын, шәһәр төзелеше нормативларын һәм кагыйдәләрен әзерләүне, дәүләт җир төзелеше кадастрын һәм шәһәр төзелеше мониторингын алып баруны финанслау;

шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыруга чыгымнарны Татарстан Республикасының республика бюджетына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдимнәр бирү;

шәһәр төзелеше өлкәсендә үз вәкаләтләренең бер өлешен, башкарма хакимиятнең федераль органнары белән килешеп, аларга тапшыру;

законнарда билгеләнгән бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

23 статья. Шәһәр төзелеше өлкәсендә халык депутатларының район Советы вәкаләтләре

Халык депутатлары район Советының шәһәр төзелешен җайга салу өлкәсендәге компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

район җирләре чикләрен үзгәртү һәм билгеләү турындагы тәкъдимнәр белән Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына мөрәҗәгать итү;

районның икътисадый һәм социаль үсеше программалары кысаларында шәһәр төзелеше гамәлләрен башкару программаларын раслау;

район территориясе, район территориясенең өлешләре үсешен шәһәр төзелеше ягыннан планлаштыру турындагы, район корылышы турындагы шәһәр төзелеше документациясен, күрсәтелгән территорияләрнең

инженерия, транспорт һәм социаль инфраструктуралары үсешенең һәм территорияләрне төзекләндерүнең схемаларын һәм проектларын раслау (махсус җайга салынучы шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектлары булган территорияләрнең шәһәр төзелеше документациясен раслаудан тыш);

район территориясендә шәһәр төзелеше турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору;

җир кишәрлекләрен төзү, районда аларны зоналаштыру кагыйдәләрен законнар нигезендә кабул итү һәм үзгәртү;

шәһәр төзелеше өлкәсендә үз вәкаләтләренең бер өлешен, башкарма хакимиятнең республика органнары белән килешеп, аларга тапшыру;

шәһәр төзелеше өлкәсендә үз вәкаләтләренең бер өлешен район администрациясенә тапшыру.

24 статья. Шәһәр төзелеше өлкәсендә халык депутатларының шәһәр һәм берләштерелгән Советы вәкаләтләре

Шәһәр төзелеше өлкәсендә халык депутатларының шәһәр һәм берләштерелгән Советы компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

шәһәр җирләренең чикләрен билгеләү һәм үзгәртү турындагы тәкъдимнәрне, шәһәр читләре проектын һәм аларны раслау турындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертү;

шәһәрдәге район җирләренең чикләрен билгеләү;

шәһәрнең икътисадый һәм социаль үсеше программалары кысаларында шәһәр төзелеше гамәлләрен башкару программаларын раслау;

шәһәрнең (махсус җайга салынучы объектлары булган шәһәрләрдән гайре) генераль планын, шәһәр территориясе үсешен шәһәр төзелеше ягыннан планлаштыру турындагы һөм аның корылышы турындагы бүтән төрле шәһәр төзелеше документациясен, күрсәтелгән территорияләрнең инженерия, транспорт һәм социаль инфраструктуралары үсешенең һәм шул территорияләрне төзеклөндерүнең схемаларын һәм проектларын раслау;

шәһәрнең шәһәр төзелеше уставын, аңа үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне раслау;

җир кишәрлекләрен кору, шәһәрдә аларны зоналаштыру кагыйдәләрен законнар нигезендә кабул итү һәм үзгәртү;

шәһәр территориясендә шәһәр төзелеше турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору;

шәһәр төзелеше өлкәсендә үз вәкаләтләренең бер өлешен халык депутатларының шәһәрдәге район Советларына тапшыру.

**25 статья.** Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә район администрациясе вәкаләтләре

Район администрациясенең шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

районның шәһәр төзелеше программаларын әзерләү һәм үтәү;

шәһәр төзелеше өлкәсендә районның норматив хокукый актларын кабул итү һәм үзгәртү;

җир кишәрлекләрен төзү кагыйдәләрен эшләү һәм, район территориясендә шәһәр төзелеше законнары бозылган очракта, объектлар төзүне һәм эксплуатацияләүне туктатып тору турында карарлар кабул итү;

район территориясе, район территориясенең өлешләре үсешен шәһәр төзелеше ягыннан планлаштыру турындагы, район корылышы турындагы шәһәр төзелеше документациясен, күрсәтелгән территорияләрнең инженерия, транспорт һәм социаль инфраструктуралары үсешенец һәм территорияләрне төзекләндерүнең схемаларын һәм проектларын эшләү һәм гамәлгә ашыру;

район администрациясенә тиешле вәкаләтләр бирелгән очракта, шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектларының дәүләт шәһәр төзелеше кадастрын һәм мониторингын алып баруны оештыру;

күчемсез объектлар төзү өчен билгеләнгән тәртиптә рөхсәтләр бирү;

шәһәр төзелеше өлкәсендә җирле үзидарә органнарынын норматив хокукый актлары үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

шәһәр төзелеше өлкәсендә кабул ителүче һәм кабул ителгән карарлар турында халыкка хәбәр итү, шәһәр төзелеше өлкәсендәге мәсьәләләр буенча референдумнар оештыру һәм уздыру;

район территориясе үсешен шәһәр төзелеше ягыннан планлаштыру турында шәһәр төзелеше документациясен әзерләү буенча заказчылар функцияләрен башкару, шулай ук заказчы функцияләрен архитектура һәм шәһәр төзелешенең республика органына тапшыру;

район территориясендәге җирләрне, башка күчемсез объектларны инвентаризацияләүне оештыру һәм уздыру;

шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге бәхәсләрне үз компетенциясе чикләрендә хәл итү;

район территориясе үсешен шәһәр төзелеше ягыннан планлаштыру турында документация әзерләүне һәм гамәлгә ашыруны финанслау;

шәһәр төзелеше өлкәсендә район территориясендә кабул ителүче норматив хокукый актларның үтәлешен үз компетенциясе чикләрендә тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

район территориясендә, архитектура һәм шәһәр төзелешенең республика органы белән килештереп, архитектура һәм шәһәр төзелеше органнары турында нигезләмәләр раслау;

шәһәр төзелеше өлкәсендә үз вәкаләтләренең бер өлешен җирле үзидарә органнарына тапшыру;

үз карамагындагы җирләрдән шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен бүлеп бирелгән җир кишәрлекләрендә халык ихтыяҗларын тәэмин итү турында карарлар кабул итү;

шәһәр төзелеше өлкәсендәге бүтән вәкаләтләрне законнар нигезендә гамәлгә ашыру.

<u>26 статья.</u> Шәһәр төзелеше өлкәсендә шәһәр администрациясе вәкаләтләре

Шәһәр төзелеше өлкәсендә шәһәр администрациясе компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

төзелеш кагыйдәләрен эшләү, кабул итү һәм үзгәртү;

шәһәр территориясе үсешен шәһәр төзелеше ягыннан планлаштыру турындагы һәм аның корылышы турындагы шәһәр төзелеше документациясен, күрсәтелгән территорияләрнең инженерия, транспорт һәм социаль инфраструктуралары үсешенең һәм территорияләрне төзекләндерүнең схемаларын һәм проектларын эшләү һәм гамәлгә ашыру;

шәһәр чите проектларын эшләү һәм аларны раслау турындагы тәкъдимнәрне дәүләт хакимиятенең җирле органнарына кертү;

администрациягә тиешле вәкаләтләр бирелгән очракта, шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектларының дәүләт шәһәр төзелеше кадастрын һәм мониторингын алып баруны оештыру;

күчемсез объектлар төзү өчен билгеләнгән тәртиптә рөхсәтләр бирү;

шәһәр төзелеше өлкәсендә кабул ителүче һәм кабул ителгән карарлар турында халыкка хәбәр итү, шәһәр төзелеше өлкәсендәге мәсьәләләр буенча законнар нигезендә референдумнар оештыру һәм уздыру;

шәһәр территориясе үсешен шәһәр төзелеше ягыннан планлаштыру турындагы һәм аның корылышы турындагы шәһәр төзелеше документациясен әзерләү буенча заказчылар функцияләрен башкару;

шәһәрдәге җирләрне, күчемсез башка объектларны инвентаризацияләүне оештыру һәм уздыру;

коммуналь милектәге яисә үз карамагындагы җирләрдән шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен бүлеп бирелгән җир кишәрлекләрендә халык ихтыяҗларын тәэмин итү турында карарлар кабул итү;

шәһәр төзелеше өлкәсендәге бәхәсләрне үз компетенциясе чикләрендә хәл итү;

архитектура һәм шәһәр төзелешенең республика органы белән килештереп, шәһәрдә архитектура һәм шәһәр төзелеше органнары турындагы нигезләмәләрне раслау;

шәһәр торак пунктлары территорияләре үсешен шәһәр төзелеше ягыннан планлаштыру турындагы шәһәр төзелеше документациясен, фәнни-тикшеренү эшләре уздыру программаларын әзерләүне һәм гамәлгә ашыруны, шулай ук шәһәр төзелеше өлкәсендә норматив хокукый актлар проектларын әзерләүне финанслау;

шәһәр төзелеше өлкәсендә үз вәкаләтләренең бер өлешен шәһәрдәге район администрациясенә, җирле үзидарә органнарына тапшыру;

шәһәр төзелеше өлкәсендәге бүтән вәкаләтләрне законнар нигезендә гамәлгә ашыру.

<u>27 статья.</u> Җирле үзидарә карамагындагы шәһәр төзелеше өлкәсе предметлары

Җирле үзидарә органнары законнар нигезендә үз карамакларындагы территория чикләрендә шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыруны тәэмин итәләр.

IV бүлек. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген җайга салу өлкәсендә Татарстан Республикасының дәүләт идарәсе органнары системасы һәм аларның вәкаләтләре

<u>28 статья.</u> Шәһәр төзелеше эшчәнлеген җайга салу өлкәсендә Татарстан Республикасының дәүләт идарәсе органнары системасы

1. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген җайга салу өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнары составына түбәндәгеләр керә:

Татарстан Республикасының архитектура һәм шәһәр төзелеше органы;

районнарның, республика буйсынуындагы шәһәрләрнең архитектура һәм шәһәр төзелеше органнары, шулай ук законнар нигезендә төзелүче бүтән архитектура һәм шәһәр төзелеше органнары (архитектура һәм шәһәр төзелешенең җирле органнары);

шәһәр төзелеше һәм проектлау документациясен ведомстводан тыш дәүләт экспертизалау органнары.

2. Архитектура һәм шәһәр төзелешенең җирле органнары тиешле органнарның карары буенча төзеләләр һәм үз эшләрен билгеләнгән тәртиптә законнар нигезендә оештыралар.

3. Архитектура һәм шәһәр төзелеше җирле органнарының структурасы һәм саны, торак пунктлары статусыннан һәм халык саныннан чыгып, Татарстан Республикасы район һәм шәһәр администрацияләренең үрнәк структурасы нигезендә билгеләнә.

29 статья. Татарстан Республикасының архитектура һәм шәһәр төзелеше органы вәкаләтләре

1. Татарстан Республикасының архитектура һәм шәһәр төзелеше органы:

Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына шәһәр төзелеше өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарының һәм бүтән норматив хокукый актларының проектларын, аларны әзерләү турында тәкъдимнәр кертә;

Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше өлкәсендә дәүләт сәясәте эшләүне һәм аны гамәлгә ашыруны оештыра;

территория шәһәр төзелеше нормативларын һәм кагыйдәләрен эшләүне һәм бастырып чыгаруны оештыра;

шәһәр төзелеше өлкәсендә фәнни-тикшеренү, проектлау һәм эзләнү оешмаларының эшләрен җайга сала;

Татарстан Республикасы территориясе үсешен шәһәр төзелеше ягыннан планлаштыру турында шәһәр төзелеше документациясен эшләүне, Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр төзелеше өлкәсендә фәнни-тикшеренү эшләре уздыруны, шулай ук дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары һәм җирле үзидарә органнары заказы буенча шәһәр төзелеше өлкәсендә гамәлгә ашырылучы фәнни-тикшеренү эшләренең шәһәр төзелеше документациясен әзерләүне һәм шул эшләрне башкаруны тәэмин итә;

республика максатчан программаларының һәм Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше программаларының шәһәр төзелеше бүлекләрен эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнаша;

архитектура һәм шәһәр төзелеше җирле органнарының эшчәнлеген җайга салуны һәм фәнни-ысулый тәэминат өлешендә аларның эшчәнлегенә җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра;

шәһәр төзелеше һәм проект документациясен әзерләү эшчәнлеген, архитектура эшчәнлеген (Россия Федерациясе Архитекторлар берлегенең төбәк бүлекчәләре белән берлектә), төзелеш өчен инженерлык эзләнүләрен башкару эшчәнлеген, шулай ук шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашырганда топография-геодезия һәм картография эшләрен лицензияләүне, лицензияләү вәкаләтләре Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнарына билгеләнгән тәртиптә тапшырылган шәһәр төзелеше өлкәсендәге бүтән эшчәнлекне лицензияләүне гамәлгә ашыра;

республика әһәмиятенә ия күчемсез объектларны төзүгә рөхсәтләр алу максатларында документлар әзерләүне, шулай ук төзелеш өчен инженерия эзләнүләрен башкару этапларын билгеләнгән тәртиптә теркәүне гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасы территориясенең үсешен шәһәр төзелеше ягыннан планлаштыру турында шәһәр төзелеше документациясен әзерләүне

һәм гамәлгә ашыруны тикшереп тора һәм аларны әзерләүчеләргә бу документларны Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнары белән килештерүдә ярдәм итә;

шәһәр төзелеше документациясен әзерләү өчен билгеләнгән тәртиптә шәһәр төзелеше йөкләмәләрен килештерә;

шәһәр төзелеше документациясенә, фәнни-тикшеренү эшләренә, максатчыл республика программаларының һәм территориянең социаль-икътисадый үсеше программаларының шәһәр төзелеше буенча бүлекләренә, территорияләрнең инженерия, транспорт һәм социаль инфраструктуралары һәм территорияләрне төзекләндерү схемаларына һәм проектларына дәүләт экспертизасын уздыруны тәэмин итә;

Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр төзелеше һәм проектлау документациясен әзерләүгә конкурслар оештыра;

тиешле территорияләрдә шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектларының дәүләт шәһәр төзелеше кадастрын һәм мониторингын алып баруны, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган шәһәр төзелеше документациясен теркәүне гамәлгә ашыра;

тиешле территорияләрдә төзелеш өчен инженерия эзләнүләренең архив фондларын оештыруны һәм алып баруны гамәлгә ашыра;

шәһәр һәм авыл торак пунктларының, тиешле территорияләрдә махсус җайга салынучы шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектларының чикләрен билгеләү һәм үзгәртү турындагы тәкъдимнәрне карый;

шәһәр һәм авыл торак пунктларындагы җирләрдән файдалануны һәм аларны саклауны үз компетенциясе чикләрендә дәүләт тарафыннан тикшереп торуны гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасының Җир ресурслары һәм җир реформасы органы белән берлектә, җирләрне инвентаризацияләү, җир кишәрлекләрен коммуналь, хосусый милеккә һәм җирле үзидарә милкенә, файдалануга һәм арендага тапшыру буенча материаллар әзерләүдә катнаша;

шәһәр төзелеше турындагы Татарстан Республикасы законнарының үтәлешен үз компетенциясе чикләрендә тикшереп тора;

гражданнарны, архитектура һәм шәһәр төзелеше җирле органнарын шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге мәгълүмат белән тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

архитектура эшчәнлеге турындагы законнарда билгеләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра;

шәһәр төзелеше өлкәсендәге халыкара хезмәттәшлектә катнаша.

2. Татарстан Республикасы законнары һәм бүтән норматив хокукый актлары белән Татарстан Республикасы архитектура һәм шәһәр төзелеше органының өстәмә вәкаләтләре дә билгеләнергә мөмкин.

30 статья. Шәһәр төзелеше өлкәсендә архитектура һәм шәһәр төзелеше җирле органы вәкаләтләре

1. Архитектура һәм шәһәр төзелеше җирле органы түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

шәһәр һәм авыл торак пунктлары, җирле үзидарәнең башка берәмлекләре территорияләренең үсешен шәһәр төзелеше ягыннан планлаштыру турындагы һәм аларның корылышы турындагы шәһәр төзелеше документациясен билгеләнгән тәртиптә әзерләүне, экспертизалауны, карауны, иҗтимагый фикер алышуны, килештерүне һәм раслауга тәкъдим итүне, шәһәр төзелеше өлкәсендә фәнни-тикшеренү эшләре уздыруны тәэмин итә;

Татарстан Республикасы территориясе һәм Татарстан Республикасы территориясенең өлешләре үсешен шәһәр төзелеше ягыннан планлаштыруның Территория комплекслы схемасын, Татарстан Республикасы территориясенең инженерия, транспорт һәм социаль инфраструктуралары үсешенең һәм территорияне төзекләндерүнең схемаларын һәм проектларын, республика максатчыл программаларының һәм социаль-икътисадый үсеш буенча республика программаларының шәһәр төзелеше бүлекләрен карауда һәм килештерүдә катнаша;

максатчыл җирле программаларның һәм социаль-икътисадый үсеш буенча җирле программаларның шәһәр төзелеше бүлекләрен әзерләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнаша;

дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары белән килештереп, шәһәр төзелеше документациясенең заказчы функцияләрен Татарстан Республикасы архитектура һәм шәһәр төзелеше органына тапшыра ала;

шәһәр төзелеше документациясен әзерләүне һәм гамәлгә ашыруны тикшереп тора һәм бу документацияне дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары белән килештерүдә аны әзерләүчегә ярдәм итә;

корылыш кагыйдәләрен һәм шәһәр төзелеше өлкәсендәге башка җирле норматив хокукый актларны әзерләүне тәэмин итә;

күчемсез объектларны төзүгә рөхсәтләр, шулай ук төзелеш өчен инженерия эзләнүләрен башкаруга рөхсәтләр бирү максатларында билгеләнгән тәртиптә документлар әзерләүне һәм аларның үтәлешен теркәүне гамәлгә ашыра;

шәһәр төзелеше документациясен әзерләү өчен билгеләнгән тәртиптә шәһәр төзелеше йөкләмәләре бирә;

шәһәр төзелеше һәм проектлау документациясе әзерләүгә, тиешле территорияләрне архитектура-сәнгать ягыннан бизәүгә һәм төзекләндерүгә конкурслар оештыра;

граждани торак, җитештерү, коммуналь һәм табигатьне саклау билгеләнешендәге объектларга, инженерия һәм транспорт инфраструктуралары объектларына, шулай ук тиешле территорияләрне

төзекләндерүгә карата проект документациясен билгеләнгән тәртиптә килештерә;

шәһәр, авыл һәм башка торак пунктлар территорияләрендә гамәлдәге корылыш планын (таяну планын), корылмаларны һәм коммуникация элемтәләрен, инженерия җиһазларын урнаштыруның теркәү планын, шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектларының дәүләт шәһәр төзелеше кадастрын, мониторингын, шулай ук төзелеш өчен инженерия эзләнүләренең архив фондын алып баруны гамәлгә ашыра;

төзелеш өчен җир кишәрлекләрен сайлау турында, гамәлдәге төзелешләрне шәһәр төзелеше документациясе нигезендә реконструкцияләү яисә аларны төзекләндерү, шулай ук күрсәтелгән җир кишәрлекләренең чикләрен билгеләү турында тәкъдимнәр әзерләүдә катнаша;

күчемсез объектларны төзү һәм реконструкцияләү өчен җир кишәрлекләре бирү турында җирле администрация органнары карарлары проектларын әзерләүдә, шулай ук тиешле график һәм текст материалларын әзерләүдә катнаша;

төзелешне, югары билгеләрне, биналарның нигезләрен, корылмаларны һәм җайланмаларны, инженерия коммуникацияләре трассаларын җайга салуның кызыл линияләрен һәм башка линияләрне натурага (җирлеккә) чыгаруны гамәлгә ашыра, шулай ук тиешле урында җир кишәрлекләренең чикләрен билгеләүдә катнаша;

шәһәр, авыл торак пунктларында һәм җирле үзидарәнең башка берәмлекләрендә, шәһәр яны зоналарында авыл хуҗалыгы ихтыяҗлары өчен файдаланылучы территорияләргә карата җир төзелеше документациясен килештерә;

шәһәр, авыл торак пунктларының һәм җирле үзидарәнең башка берәмлекләренең җирләрен һәм бүтән күчемсез объектларын инвентаризацияләү буенча эшләр башкаруда катнаша;

җир кишәрлекләренә һәм күчемсез башка объектларга конкурслар һәм аукционнар уздыру өчен документлар әзерләүдә катнаша;

тормыш эшчәнлеге мохитенең торышы турында һәм аны үзгәртү ниятләре турында халыкка хәбәр итә;

шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча гражданнарның һәм юридик затларның гаризаларын һәм мөрәҗәгатьләрен карый һәм үз компетенциясе чикләрендә карарлар кабул итә;

шәһәр, авыл торак пунктларының һәм җирле үзидарәнең башка берәмлекләренең җирләреннән файдалануны һәм аларны саклауны үз компетенциясе чикләрендә тикшереп тора;

шәһәр төзелеше турындагы законнарның һәм бүтән норматив хокукый актларның үтәлешен үз компетенциясе чикләрендә тикшереп тора.

## V бүлек. Территорияләрнең, торак пунктларның үсешен шәһәр төзелеше ягыннан планлаштыру турында һәм аларны төзү турында шәһәр төзелеше документациясе

**31 статья.** Шәһәр төзелеше документациясенең билгеләнеше һәм төрләре

1. Татарстан Республикасы территориясенең һәм торак пунктларның үсешен шәһәр төзелеше ягыннан планлаштыру, шулай ук аларны кору Татарстан Республикасы территориясенең һәм Татарстан Республикасы территориясе өлешләренең, шәһәр, авыл торак пунктлары һәм җирле үзидарәнең башка берәмлекләре территорияләренең үсешен шәһәр төзелеше ягыннан планлаштыру турында һәм аларны кору турында шәһәр төзелеше документациясен әзерләү юлы белән гамәлгә ашырыла.

2. Татарстан Республикасы территориясенең һәм Татарстан Республикасы территориясе өлешләренең үсешен шәһәр төзелеше ягыннан планлаштыру турында шәһәр төзелеше документациясенә Татарстан Республикасы территориясенең, шәһәр яны зоналарының, башка территорияләренең (алга таба - Татарстан Республикасы территориясенең һәм Татарстан Республикасы территориясе өлешләренең үсешен шәһәр төзелеше ягыннан планлаштыруның территория комплекслы схемалары) үсешен шәһәр төзелеше ягыннан планлаштыру буенча территория комплекслы схемасы керә.

Татарстан Республикасы территориясенең һәм Татарстан Республикасы территориясе өлешләренең үсешен шәһәр төзелеше ягыннан планлаштыру турындагы шәһәр төзелеше документациясендә Татарстан Республикасының һәм торак пунктларның шәһәр төзелеше өлкәсендәге үзара мәнфәгатьләре билгеләнә.

3. Шәһәр, авыл торак пунктларының һәм җирле үзидарәнең башка берәмлекләренең территорияләре өчен шәһәр төзелеше документациясенә шәһәр, авыл торак пунктларының һәм җирле үзидарәнең башка берәмлекләренең территорияләре үсешен шәһәр төзелеше ягыннан планлаштыру турындагы шәһәр төзелеше документациясе (генераль планнары) һәм шәһәр һәм авыл торак пунктлары территорияләрен кору турындагы шәһәр төзелеше документациясе керә.

Шәһәр, авыл торак пунктларының һәм җирле үзидарәнең башка берәмлекләренең территорияләре үсешен шәһәр төзелеше ягыннан планлаштыру турындагы шәһәр төзелеше документациясенә түбәндәгеләр керә:

шәһәр һәм авыл торак пунктларының генераль планнары;

шәһәр, авыл торак пунктларының һәм җирле үзидарәнең башка берәмлекләренең читләре проектлары.

Шәһәр һәм авыл торак пунктлары территорияләрен кору турындагы шәһәр төзелеше документациясенә түбәндәгеләр керә:

шәһәр һәм авыл торак пунктлары территорияләренең өлешләрен планлаштыру проектлары (алга таба - планлаштыру проекты);

территорияләрнең ызан проектлары;

кварталларның, микрорайоннарның, шәһәр һәм авыл торак пунктлары структураларының бүтән планлаштыру элементларын кору проектлары (алга таба - кору проектлары).

4. Шәһәр төзелеше эшчәнлегенең һәр объектына шәһәр төзелеше нормативлары, экологик һәм башка нормативлар нигезендә әзерләнүче шәһәр төзелеше документациясенең аерым төре туры килә. Шәһәр төзелеше документациясенең теләсә кайсы төренә текстлы һәм график материаллар керә, анда тиешле төрдәге шәһәр төзелеше документын әзерләү йөкләмәсендә билгеләнгән мәҗбүри нигезләмәләр була. Аны килештерү һәм раслау тәртибе әлеге Кодекс, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган бүтән норматив хокукый актлар белән билгеләнә.

5. Шәһәр төзелешенең теләсә кайсы төрдәге документациясе экологик эспертиза турындагы законнарда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә дәүләт экология экспертизасын узарга тиеш.

Шәһәр төзелешенең теләсә кайсы төрдәге документациясен раслау өчен мәҗбүри шартлар аны санитария-эпидемиология күзәтчелегенең тиешле органнары белән килештерүдән, шулай ук тарихи һәм мәдәни ядкярләрне саклау өлкәсендәге законнарда билгеләнгән очракларда мәдәният ядкярләрен саклау органнарының, кызыксынучы бүтән дәүләт органнарының халык фикере исәпкә алынган уңай бәяләмәсе булудан гыйбарәт.

6. Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, төбәк үзенчәлекләреннән һәм җирле шартлардан чыгып, шәһәр төзелеше документациясенең башка төрләре дә билгеләнергә мөмкин, моңа шәһәр төзелешенең әлеге статьяның 3 һәм 4 пунктларында билгеләнгән документациясе төрләре керми.

7. Шәһәр төзелешенең теләсә кайсы төрдәге документациясе дәүләт хакимияте һәм идарәсенең тиешле органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелгән йөкләмәләр нигезендә яисә, алар белән килештереп, заказчылар тарафыннан әзерләнә.

Шәһәр төзелешенең теләсә кайсы төрдәге документациясен әзерләү йөкләмәсенә кирәк очракта проектка кадәр фәнни-тикшеренү эшләрен һәм инженерия эзләнүләрен уздыру кертелергә мөмкин.

8. Шәһәр төзелешенең теләсә кайсы төрдәге расланган документациясенә үзгәрешләр кертү бары тик шәһәр төзелешенең шушы документациясен раслаган органнары карары буенча гына гамәлгә ашырыла, аны матбугатта бастырып чыгару һәм, мондый үзгәрешләр кертү халык

мәнфәгатьләренә кагылганга күрә, халык катнашында фикер алышу уздырылуы шарт.

9. Шәһәр төзелешенең теләсә кайсы төрдәге расланган документациясе конкурс нигезендә әзерләнергә мөмкин.

Шәһәр төзелешенең теләсә кайсы төрдәге расланган документациясе теркәлү һәм саклану өчен архитектура һәм шәһәр төзелешенең тиешле органына тапшырылырга тиеш.

10. Шәһәр төзелешенең теләсә кайсы төрдәге документациясен әзерләү билгеләнгән тәртиптә бирелгән тиешле лицензия булганда гамәлгә ашырыла.

11. Шәһәр төзелешенең теләсә кайсы төрдәге документациясен әзерләү яисә аңа үзгәрешләр кертү турында дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, җирле үзидарә органнары карары, шулай ук шәһәр төзелешенең теләсә кайсы төрдәге документациясенең төп нигезләмәләре матбугатта басылып чыгарга тиеш.

12. Шәһәр төзелешенең теләсә кайсы төрдәге әзерләнеп килүче документациясе буенча халык катнашында фикер алышу уздыру тәртибе Татарстан Республикасы законнары һәм башка төрле норматив хокукый актлары белән һәм җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

13. Шәһәр төзелешенең территорияләр һәм торак пунктлар үсешенең шәһәр төзелешен планлаштыру турындагы документациясе федераль, республика һәм җирле максатчан программаларны, Татарстан Республикасы территориясенең, торак пунктлар территорияләренең социаль-икътисадый үсеше программаларын әзерләгәндә, инженерия, транспорт һәм социаль инфраструктуралар үсеше схемаларын һәм проектларын, табигатьне саклауның һәм табигатьтән файдалануның территория комплекслы схемаларын, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр йогынтысына дучар булган территорияләрне яклау схемаларын әзерләгәндә исәпкә алына.

<u>32 статья.</u> Шәһәр төзелеше документациясенең дәүләт экспертизасы

1. Шәһәр төзелеше документациясе расланганчыга кадәр әлеге Кодекста һәм Татарстан Республикасының Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдәге бүтән норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә дәүләт экспертизасы узарга тиеш.

2. Шәһәр төзелеше документациясенә дәүләт экспертизасы әлеге документациянең шәһәр төзелеше турындагы законнар таләпләренә туры килү-килмәвен билгеләү максатларында гамәлгә ашырыла.

3. Шәһәр төзелеше документациясенә дәүләт экспертизасы шәһәр төзелешенә һәм проект документациясенә дәүләт экспертизасын уздыручы органнар тарафыннан законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Шәһәр төзелеше һәм проект документациясенә дәүләт экспертизасын уздыручы республика органы тарафыннан шәһәр төзелеше документациясенә, фәнни-тикшеренү эшләренә, республика һәм җирле максатчан программаларының, Татарстан Республикасының, район һәм торак пунктлар территорияләренең социаль-икътисадый үсеше программаларының шәһәр төзелеше бүлекләренә, шулай ук территорияләрнең инженерия, транспорт һәм социаль инфраструктуралар үсеше һәм төзекләндерү схемаларының һәм проектларының шәһәр төзелеше таләпләрен үтәү өлешенә гамәлдәге законнар нигезендә дәүләт экспертизасы уздырыла.

4. Шәһәр төзелеше һәм проект документациясенең республика дәүләт экспертизасы органы бәяләмәсе дәүләт экология экспертизасының, җир ресурслары һәм җир реформасы органнарының, мәдәният ядкярләрен саклау, җир асты байлыкларыннан файдалану буенча дәүләт фонды идарәсе, санитария-эпидемиология күзәтчелеге, янгынга каршы дәүләт хезмәте махсус вәкаләтле органнарының, җир асты байлыкларын саклау органнарының, шулай ук законнар нигезендә шәһәр төзелеше һәм проект документациясен әзерләү йөкләмәсендә исемлеге билгеләнә торган бүтән кызыксынучы дәүләт органнарының бәяләмәләренә нигезләнергә тиеш.

5. Шәһәр төзелеше һәм проект документациясенә республика дәүләт экспертизасы органының уңай бәяләмәсе шәһәр төзелеше һәм проект документациясен раслау өчен нигез була.

**33 статья.** Республика һәм җирле максатчан программаларны һәм Татарстан Республикасы территориясенең һәм торак пунктлар территорияләренең социаль-икътисадый үсеше программаларын әзерләүгә карата шәһәр төзелешенең төп таләпләре

Республика һәм җирле максатчан программаларны һәм Татарстан Республикасы территориясенең, торак пунктлар территорияләренең социаль-икътисадый үсеше программаларын әзерләгәндә түбәндәге өлешләргә карата шәһәр тозелеше таләпләре исәпкә алынырга тиеш:

әлеге программаларда күрсәтелгән гамәлләрнең шәһәр төзелеше өлкәсендәге, шул исәптән инженерия, транспорт һәм социаль инфраструктура үсеше өлкәсендәге дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләренә туры килүе;

икътисад үсешенең төбәкләрнең һәм торак пунктларның комплекслы үсешенә туры килүе;

территорияләрнең һәм торак пунктларның табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр йогынтысыннан яклануын, шулай ук әйләнә-тирә табигать мохитен саклауны һәм табигатьтән нәтиҗәле файдалануны тәэмин итү;

тарихи-мәдәни һәм табигый мирас объектлары территорияләрен саклау һәм махсус сакланылучы объектлар биләгән җирләрнең хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен алынуын булдырмау;

инженерия, транспорт һәм социаль инфраструктуралар объектларыннан инвалидлар файдалана алу өчен шартлар тудыру;

территорияләрнең һәм торак пунктларның социаль, икътисадый һәм экологик проблемаларын хәл итү максатларында дәүләт ярдәме күрсәтү чараларын билгеләү;

тиешле территорияләр һәм торак пунктлар үсешенең шәһәр төзелешен планлаштыру турындагы шәһәр төзелеше документациясен эшләү;

инженерия эзләнүләрен һәм фәнни-тикшеренү эшләрен башкару.

## VI бүлек. Татарстан Республикасы территориясе үсешенең шәһәр төзелешен планлаштыру

### 34 статья. Татарстан Республикасы территориясенең һәм аның территориясенең өлешләре үсешенең шәһәр төзелешен планлаштыру буенча комплекслы территория схемалары

1. Татарстан Республикасы территориясе һәм аның территориясе өлешләре үсешенең шәһәр төзелешен планлаштыру буенча комплекслы территория схемаларында, Татарстан Республикасының социаль-икътисадый һәм табигать-климат шартларыннан чыгып, республика территориясендәге шәһәр төзелеше өлкәсендә дәүләт сәясәте максатлары билгеләнә.

2. Татарстан Республикасы территориясе һәм аның территориясе өлешләре үсешенең шәһәр төзелешен планлаштыру буенча комплекслы территория схемаларында Татарстан Республикасы территориясен яисә аның территориясе өлешләрен зоналаштыру билгеләнә, халыкны урнаштыру системасын камилләштерүне үстерүнең , шәһәр һәм авыл торак пунктларын, төбәк һәм авылара әһәмияткә ия җитештерүләрне, инженерия, транспорт һәм социаль инфраструктураларны үстерүнең, Татарстан Республикасы территориясенең яисә аның территориясе өлешләрен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр йогынтысыннан яклауның, шәһәр төзелеше чаралары белән экологик хәлне яхшыртуның, тарихи-мәдәни һәм табигый мирас объектлары территорияләрен саклауның төп юнәлешләре билгеләнә. Әлеге комплекслы территория схемаларында торак пунктларның һәм шәһәрләрдәге шәһәр яны зоналарының чикләрен билгеләү турында, шулай ук Татарстан Республикасын территориясен яисә аның территориясе өлешләрен комплекслы үстерү максатларында ресурслар белән тәэмин итү турында тәкъдимнәр була.

3. Татарстан Республикасы территориясе һәм аның территориясе өлешләре үсешенең шәһәр төзелешен планлаштыру буенча комплекслы территория схемалары, җирле үзидарәнең кызыксынучы органнары белән

килештереп, Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнары тарафыннан әзерләнә һәм раслана.

4. Дәүләт идарәсе органнары Татарстан Республикасы территориясенең һәм аның территориясе өлешләренең үсеше буенча шәһәр төзелешен планлаштыруның территориаль комплекслы схемаларын гамәлгә ашыруда республиканың катнашу тәртибен билгелиләр.

## VII бүлек. Районнар, шәһәрләр, авыл торак пунктлары һәм җирле үзидарәнең башка берәмлекләре үсешенең шәһәр төзелешен планлаштыру

**35 статья.** Район территорияләре, район территорияләре өлешләре үсешенең шәһәр төзелешен планлаштыруның территория комплекслы схемалары

1. Район территорияләре, район территорияләре өлешләре үсешенең шәһәр төзелешен планлаштыруның Татарстан Республикасы территориясе үсешенең шәһәр төзелешен планлаштыру турындагы билгеләнгән тәртиптә расланган шәһәр төзелеше документациясе нигезендә әзерләнүче комплекслы территория схемаларында түбәндәгеләр билгеләнә:

социаль-икътисадый үсешне һәм табигать-климат шартларын исәпкә алып, шәһәр төзелеше өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре;

төрле функциональ билгеләнештәге зоналар һәм күрсәтелгән зоналарның территорияләреннән файдалануны чикләү;

территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр йогынтысыннан яклау чаралары;

авылара әһәмияткә ия инженерия, транспорт һәм социаль инфраструктураларны үстерү юнәлешләре;

торак пунктлар үсеше өчен резерв территорияләр;

индивидуаль торак төзелеше, дачалар, бакчачылык, яшелчәчелек тәзелешләре өчен территорияләр;

халыкның ял итү урыннарын оештыру өчен территорияләр;

район территорияләре һәм район территорияләре өлешләрен үстерү буенча бүтән чаралар.

Район территорияләре, район территорияләренең өлешләре үсешенең шәһәр төзелешен планлаштыруның комплекслы территория схемаларында торак пунктларның һәм шәһәрләрдәге шәһәр яны зоналарының чикләрен билгеләү турында, шулай ук күрсәтелгән район территорияләрен, район территорияләренең өлешләрен комплекслы үстерү максатларында ресурслар белән тәэмин итү турында тәкъдимнәр була.

2. Район территорияләре, район территорияләренең өлешләре үсешенең шәһәр төзелешен планлаштыру буенча комплекслы территория схемалары, районнар һәм район территорияләре өлешләре чикләрендәге торак пунктларның җирле үзидарә органнары белән килештереп, әлеге Кодекста билгеләнгән тәртиптә хакимият һәм идарәнең тиешле органнары тарафыннан әзерләнә һәм раслана.

3. Район территорияләре, район территорияләренең өлешләре үсешенең шәһәр төзелешен планлаштыру буенча комплекслы территория схемаларын әзерләү йөкләмәсендә дәүләт мәнфәгатьләрен исәпкә алу максатларында Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнары исемлеге билгеләнә, шулар нигезендә әлеге комплекслы территория схемалары әзерләнә һәм раслана.

<u>36 статья.</u> Шәһәр һәм авыл торак пунктларының генераль планнары

1. Генераль план - шәһәр һәм авыл торак пунктлары территорияләре үсешенең шәһәр төзелешен планлаштыру турындагы шәһәр төзелеше документациясе ул. Генераль план Татарстан Республикасының билгеләнгән тәртиптә расланган шәһәр төзелеше документациясе нигезендә эшләнә.

Генераль план халык һәм дәүләт мәнфәгатьләрендә шәһәр һәм авыл торак пунктлары территорияләренең тормыш эшчәнлеге мохитен, үсеш юнәлешләрен һәм чикләрен формалаштыру шартларын, территорияләрне зоналаштыруны, инженерия, транспорт һәм социаль инфраструктураны үстерүне, тарихи-мәдәни мирас объектларын һәм махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклауга карата, экология һәм санитария иминлегенә карата шәһәр төзелеше таләпләрен, шулай ук тормыш эшчәнлегендә янгынга каршы кирәкле шартларны билгеләүче төп шәһәр төзелеше документыннан гыйбарәт.

2. Шәһәр һәм авыл торак пунктларының генераль планында түбәндәгеләр билгеләнә:

шәһәр яисә авыл торак пунктларынын социаль-икътисадый үсеше үзенчәлекләрен, табигать-климат шартларын, халкының санын исәпкә алып, торак пунктлар территориясен үстерүнең төп юнәлешләре;

төрле функциональ билгеләнештәге зоналар һәм күрсәтелгән зоналар территорияләреннән файдалануга чикләүләр;

шәһәр яисә авыл торак пунктлары территорияләрен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр йогынтысыннан саклау, инженерия, транспорт һәм социаль инфраструктураларны үстерү чаралары;

шәһәр яисә авыл торак пунктларының корылып беткән һәм корылып бетмәгән территорияләре чагыштырмасы;

шәһәр яисә авыл торак пунктларын үстерү өчен резерв территорияләр;

шәһәр яисә авыл торак пунктлары территорияләрен үстерү буенча бүтән чаралар.

Шәһәр һәм авыл торак пунктларының генераль планнарында торак пунктларның чикләрен билгеләү турында, шулай ук торак пунктларның территорияләрен комплекслы үстерү максатларында ресурслар белән тәэмин итү турында тәкъдимнәр була.

3. Шәһәрнең һәм аның шәһәр яны зонасының генераль планы дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары, җирле үзидарә органнары белән чиктәш территорияләр арасында килешү төзү нигезендәге бердәй документ буларак әзерләнергә мөмкин.

4. Илле меңгә кадәр халкы булган шәһәрнең генераль планы һәм авыл торак пунктының генераль планы күрсәтелгән торак пунктларның территорияләрен планлаштыру проекты белән бергә бердәй документ буларак әзерләнергә мөмкин.

5. Тарихи торак пунктның генераль планын әзерләгәндә шундый торак пунктның төп тарихи-архитектура планы һәм тарих, мәдәният ядкярләрен саклау зоналарының проектлары исәпкә алына.

6. Шәһәр һәм авыл торак пунктларының генераль планнары әлеге Кодекста билгеләнгән тәртиптә дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары, тиешле торак пунктларның җирле үзидарә органнары тарафыннан әзерләнә һәм раслана.

Шәһәрнең һәм аның шәһәр яны зонасының генераль планы әлеге Кодекста билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан раслана.

7. Шәһәр яисә авыл торак пунктларының генераль планы расланганчы ул матбугатта бастырып чыгарылырга һәм Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең кызыксынучы органнары, җирле үзидарә органнары, экологик экспертиза өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органнары, шулай ук кызыксынучы оешмалар һәм халык белән килештерелергә тиеш (әлеге Кодексның 18 һәм 31 статьялары).

Шәһәр яисә авыл торак пунктларының генераль планын әзерләү йөкләмәсендә дәүләт мәнфәгатьләрен исәпкә алу максатларында дәүләт хакимияте һәм идарәсе тиешле органнарының исемлеге билгеләнә, шулар нигезендә әлеге генераль план әзерләнә һәм раслана.

8. Шәһәр яисә авыл торак пунктының яңа генераль планын эшләү чорында элек расланган генераль планның корылыш кагыйдәләренә каршы килми торган өлеше гамәлдә була.

9. Шәһәр төзелеше турындагы законнарны үзгәрткән очракта шәһәр яисә авыл торак пунктының генераль планына тиешле үзгәрешләр кертелә.

<u>37 статья.</u> Шәһәр, авыл торак пунктлары һәм җирле үзидарәнең башка берәмлекләре читләренең проектлары

1. Шәһәр, авыл торак пунктлары һәм җирле үзидарәнең башка берәмлекләре читләренең проектлары шәһәр, авыл һәм җирле үзидарәнең

башка берәмлекләре генераль планнары яисә район территорияләре, район территорияләре өлешләре үсешенең шәһәр төзелешен планлаштыру буенча комплекслы территория схемалары нигезендә эшләнә.

Кечкенә шәһәрләрнең һәм поселокларның читләре, авыл торак пунктларының читләре проектлары шушы торак пунктларның генераль планнары составында эшләнергә мөмкин.

2. Шәһәр, авыл торак пунктларының һәм җирле үзидарәнең башка берәмлекләренең читләре проектлары әлеге Кодекста билгеләнгән тәртиптә дәүләт идарәсе органнары, тиешле торак пунктның җирле үзидарә органнары тарафыннан эшләнә.

3. Шәһәр, авыл торак пунктлары һәм җирле үзидарәнең башка берәмлекләре читләре проектлары, чиктәш территорияләрнең җирле үзидарә органнары белән килештереп, Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнары тарафыннан раслана.

4. Шәһәрләр, авыллар һәм җирле үзидарәнең башка берәмлекләре читләре проектларын раслау, күрсәтелгән торак пунктларның һәм берәмлекләрнең читләре үзгәртелгәндә үз мәнфәгатьләренә кагылучы халыкның фикерен исәпкә алмыйча, рөхсәт ителми.

<u>38 статья.</u> Шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен территорияләрне зоналаштыру

1. Территорияләр һәм торак пунктлар үсешенең шәһәр төзелешен планлаштыру турындагы һәм аларны кору турындагы шәһәр төзелеше документациясен әзерләгәндә территорияләрне зоналаштыру схемасы эшләнә, аларда шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен территорияләрдән файдалану төрләре һәм алардан файдалануга чикләүләр билгеләнә.

2. Территорияләрне зоналаштыру тормыш эшчәнлегенең уңай мохитен тәэмин итүгә, территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр йогынтысыннан яклауга; халыкның һәм житештерүнең чамадан тыш концентрациясен, әйләнә-тирә мохитнең пычрануын булдырмауга; махсус сакланылучы табигать территорияләрен, шул исәптән табигый ландшафтларны, тарихи-мәдәни объектлар территорияләрен, шулай ук авыл хуҗалыгы җирләрен һәм урманнарны саклауга һәм файдалануга юнәлдерелгән.

3. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен территорияләрдән файдалануны чикләү түбәндәге зоналарда билгеләнә:

тарих һәм мәдәният ядкярләрен, тарихи-мәдәни комплексларны һәм объектларны саклау зоналары, тыюлык зоналары;

махсус сакланылучы табигать территорияләре, шул исәптән санитар саклау округлары зоналары;

санитария, яклау һәм санитар яклау зоналары;

су саклау зоналары һәм яр буе яклау зоналары;

су белән тәэмин итү чыганакларын санитар саклау зоналары;

файдалы казылмалар ятмалары зоналары;

табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр йогынтысына дучар булган территорияләр;

гадәттән тыш экологик хәлләр һәм экологик бәла-казалар зоналары;

законнар нигезендә билгеләнгән бүтән зоналар.

4. Территорияләрдән файдалануга чикләүләрне исәпкә алып, территорияләрнең функциональ билгеләнеше һәм алардан файдалануның нәтиҗәлелеге билгеләнә.

5. Билгеләнгән зоналар территорияләреннән файдалану төрләре турында һәм алардан файдалануга чикләүләр турында белешмәләр төзелеш кагыйдәләренә кертелә.

## VIII бүлек. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашырганда шәһәр һәм авыл торак пунктлары территорияләреннән файдалануны җайга салу

### 39 статья. Шәһәр һәм авыл торак пунктлары территорияләре

1. Шәһәр һәм авыл торак пунктларының билгеләнгән чикләрендәге (читләрендәге) җир кишәрлекләре, шулай ук күрсәтелгән кишәрлекләр астында һәм өстендә булган барлык нәрсә шәһәр һәм авыл торак пунктларының территория нигезен тәшкил итә.

2. Шәһәр һәм авыл торак пунктлары читләре әлеге Кодекста һәм Татарстан Республикасының җир турындагы законнарында каралган тәртиптә билгеләнә һәм үзгәртелә.

3. Шәһәр һәм авыл торак пунктлары чикләрендә (читләрендә) билгеләнгән җир асты һәм һава киңлекләре дәүләт идарәсе органнары һәм җирле үзидарә органнары карамагында була, моңа түбәндәге очраклар керми:

территорияләрне зоналаштыру шартлары нигезендә яисә төзүгә рөхсәтләр нигезендә бүтән затлар карамагында булган объектларның җир асты һәм су киңлекләре өлешләре;

җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылмалар чыгару өчен һәм бүтән максатларда җир асты байлыклары турындагы законнар нигезендә билгеләнгән тәртиптә башка затларга файдалануга тапшырылган җир асты киңлекләре өлеше;

һава киңлекләре законнары нигезендә һава суднолары очып китү өчен һәм һава киңлекләреннән файдалану өлкәсендә бүтән эшчәнлек өчен файдаланучы һава киңлекләре өлеше.

40 статья. Корылыш кагыйдәләре

1. Корылыш кагыйдәләре җирле администрациянең, җирле үзидарә органнарының шәһәр һәм авыл торак пунктларының тиешле территорияләрендә шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыруның тәртибен билгели торган норматив хокукый акты булып тора.

2. Корылыш кагыйдәләре шәһәр яисә авыл торак пунктларының генераль планы йә район территорияләре, район территорияләренең өлешләре үсешенең шәһәр төзелешен планлаштыруның комплекслы территория схемалары нигезендә эшләнә һәм аларга зоналаштыру схемасы - график материаллар (төрле функциональ билгеләнештәге территория зоналары чикләре һәм мондый зоналарның код тамгасы) һәм текстлы материаллар (һәр территория зонасының шәһәр төзелеше регламентлары) керә.

3. Территория зоналарының чикләре кызыл линияләрне, табигать объектларының табигый чикләрен, җир кишәрлекләренең чикләрен һәм бүтән чикләрне исәпкә алып билгеләнә.

4. Шәһәр төзелеше регламенты белән һәр территория зонасы өчен билгеләнгән хокукый режим шунда урнашкан барлык җир кишәрлекләренә, бүтән күчемсез объектларга карата бертигез дәрәҗәдә кулланыла.

Шәһәр төзелеше эшчәнлеге махсус җайга салына торган чикләрдәге территория зоналарында кайбер күчемсез объектларга өстәмә таләпләр билгеләнергә мөмкин.

5. Шәһәр төзелеше регламентларының белешмәләре шәһәр төзелешенең дәүләт кадастрына кертелергә тиеш.

6. Корылыш кагыйдәләрен эшләү, аларны карау, аларга үзгәрешләр кертү, әлеге кагыйдәләрне эшләү турында халыкка мәгълүмат бирү, алар буенча фикер алышу, шәһәр һәм торак пунктлары һәм җирле үзидарәнең башка берәмлекләре территорияләреннән файдалану һәм аларны төзү турында гражданнарның һәм аларның берләшмәләренең тәкъдимнәрен исәпкә алу, шулай ук аларны раслау, бастырып чыгару һәм гамәлгә кертү тәртибе дәүләт идарәсенең тиешле органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.

7. Корылыш кагыйдәләрен гамәлгә керткәнче билгеләнгән тәртиптә бирелгән күчемсез объектларны төзүгә рөхсәтләр шушы рөхсәтләр гамәлдә булган чор дәвамында гамәлдә булалар, халыкның хәвефсезлек таләпләре тәэмин ителмәгән очраклар моңа керми.

8. Корылыш кагыйдәләренә карата хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылган тиешле территориядә яшәүче гражданнар, шулай ук күчемсез объект милекчеләре һәм бүтән биләүчеләр тарафыннан судка шикаять белдерелергә мөмкин.

9. Дәүләт хакимияте һәм идарәсе җирле органнары, җирле үзидарә органнары гражданнарның, аларның берләшмәләренең вәкилләре һәм

юридик затлар катнашында күчемсез объектлардан файдалануны һәм аларны үзгәртүне җайга салуның бәхәсле мәсьәләләрен хәл итү буенча комиссияләр төзергә хокуклы.

41 статья. Территория зоналарының төрләре

1. Шәһәр һәм авыл торак пунктлары территорияләрендә түбәндәге төрләрдәге территория зоналары билгеләнергә мөмкин:

торак зоналары;

иҗтимагый-эшлекле зоналар;

җитештерү зоналары;

инженерия һәм транспорт инфраструктуралары зоналары;

рекреация зоналары;

авыл хуҗалыгында файдаланылучы зоналар;

махсус билгеләнештәге зоналар;

хәрби объектлар зоналары, режимлы территорияләрнең бүтән зоналары.

2. Дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары, җирле үзидарә органнары җирле шартлар нигезендә бүтән территория зоналарын билгели, шулай ук аларга җир кишәрлекләрен һәм бүтән күчемсез объектларны кертә алалар.

3. Территория зоналарында кече зоналар билгеләнергә мөмкин, ул территорияләрдән файдалану үзенчәлекләре, җир турындагы законнарда, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау турындагы законнарда, тарих һәм мәдәният ядкярләрен саклау турындагы законнарда, бүтән законнарда билгеләнгән файдалану чикләүләрен исәпкә алып, шәһәр төзелеше регламенты белән билгеләнә.

4. Территория зоналарына мәйданнар, урамнар, транспорт юллары, җәяүле юллары, яр буйлары, скверлар, бульварлар, сулыклар һәм башка объектлар биләп торган гомуми кулланылыштагы территорияләр керергә мөмкин. Шәһәр һәм авыл торак пунктларында гомуми файдалану территорияләре халыкнын иҗтимагый мәнфәгатьләрен канәгатьләндерү өчен билгеләнә. Гомуми файдаланудагы территорияләрдән файдалану тәртибе дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.

42 статья. Торак зоналары

1. Торак зоналары күп катлы, күп фатирлы торак йортлар, кече һәм урта катлы торак йортлар, ярдәмче җир кишәрлекләре белән индивидуаль торак йортлар төзү өчен билгеләнә. Торак зоналарында санитар яклау зоналары билгеләү таләп ителми торган һәм эшчәнлекләре әйләнә-тирә табигать мохитенә зарар (шау-шу, вибрация, магнит кыры, радиация

йогынтысы, туфракны, һаваны, суны зарарлау һәм бүтән тискәре йогынтылар) китерми торган, халыкка социаль һәм мәдәни-көнкүреш хезмәте күрсәтү өчен аерым, кушып төзелгән яисә торак биналар янәшәсендә төзелгән объектлар, гыйбадәт кылу бинаалары, автомобиль транспорты тукталышлары, сәнәга, коммуналь һәм склад объектлары урнаштыру рөхсәт ителә.

2. Торак зоналарына шулай ук торак пунктлар чикләрендә (читләрендә) урнашкан бакчачылык һәм дача кооперативлары кертелә.

43 статья. Иҗтимагый-эшлекле зоналар

1. Иҗтимагый-эшлекле зоналар сәламәтлек саклау, мәдәният, сәүдә, җәмәгать туклануы, көнкүреш хезмәте күрсәтү, коммерция эшчәнлеге объектларын, шулай ук урта профессиональ һәм югары профессиональ белем учреждениеләре объектларын, административ, фәнни-тикшеренү учреждениеләре объектларын, гыйбадәт кылу биналарын һәм бүтән биналарны, корылмаларны һәм төзелмәләрне, автомобиль транспорты тукталышларын, эшлекле, финанс һәм җәмәгать активлыгы үзәкләре биналарын урнаштыру өчен билгеләнә.

2. Иҗтимагый-эшлекле зоналарда урнаштыру рөхсәт ителгән күчемсез объектлар исемлегенә торак йортлар, кунакханәләр, җир астындагы яисә күп катлы гаражлар, автомобильләргә техник хезмәт күрсәтү станцияләре, автомобильләргә ягулык салу станцияләре кертелергә мөмкин.

44 статья. Җитештерү зоналары

1. Җитештерү зоналары инженерия һәм транспорт инфраструктуралары объектларының эшчәнлеген тәэмин итүче сәнәга, коммуналь һәм склад объектларын урнаштыру, шулай ук мондый объектларның санитар-яклау зоналарын ачыклау өчен билгеләнә.

2. Җитештерү зоналарының территорияләрен төзекләндерү җитештерү объектларының милекчеләре исәбеннән гамәлгә ашырыла.

3. Сәнәга, коммуналь һәм склад объектларының санитар-яклау зонасында торак йортлар, мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләре, гомуми белем бирү учреждениеләре, сәламәтлек саклау учреждениеләре, ял итү, физкультура-савыктыру учреждениеләре һәм спорт корылмалары, бакчачылык, дача һәм яшелчәчелек кооперативлары урнаштыру, шулай ук авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү рөхсәт ителми.

45 статья. Инженерия һәм транспорт инфраструктуралары зоналары

1. Инженерия һәм транспорт инфраструктуралары зоналары тимер юл, автомобиль, елга, һава транспорты һәм торба үткәргеч транспорт, элемтә,

инженерия җиһазлары корылмаларын һәм коммуникацияләрен урнаштыру һәм эшләтү өчен билгеләнә.

2. Транспорт, элемтә, инженерия җиһазлары корылмаларының һәм коммуникацияләренең тормыш эшчәнлеге мохитенә зарарлы йогынтысын булдырмау өчен шәһәр төзелеше буенча дәүләт нормативлары һәм кагыйдәләре, шулай ук төзелешнең махсус нормативлары, кагыйдәләре нигезендә мондый объектлардан торак территорияләренә, иҗтимагый-эшлекле һәм рекреация зоналарына кадәр тиешле ара калдыру таләпләре һәм бүтән таләпләр тәэмин ителергә тиеш.

3. Транспорт, элемтә, инженерия җиһазлары корылмалары һәм коммуникацияләре өчен бүлеп алынган чиктәге территорияләр һәм аларның санитар яклау зоналары, мондый корылмаларның һәм коммуникацияләрнең техник һәм эксплуатация үзенчәлекләре исәпкә алынып, төзекләндерелергә тиеш. Әлеге территорияләрне төзекләндерү транспорт, элемтә, инженерия җиһазлары корылмаларының һәм коммуникацияләренең милекчеләренә йөкләнә.

4. Халыкның иминлегенә турыдан-туры зарарлы тәэсир итеп файдаланыла торган транспорт, элемтә, инженерия җиһазлары корылмалары һәм коммуникацияләре шәһәр һәм авыл торак пунктларыннан читтә урнаштырыла.

<u>46 статья.</u> Рекреацион зоналар

1. Рекреацион зоналар халыкның ял итү урыннарын оештыру өчен билгеләнә һәм парклардан, бакчалардан, шәһәр урманнарыннан, урман паркларыннан, пляжлардан һәм башка төрле объектлардан гыйбарәт.

2. Рекреацион зоналарның территорияләрендә савыктыру максатындагы һәм рекреацион максаттагы объектлардан файдалануга турыдан-туры бәйле булмаган сәнәга, коммуналь һәм склад объектларын төзү һәм гамәлдәгеләрен киңәйтү рөхсәт ителми.

<u>47 статья.</u> Авыл хуҗалыгы файдалануындагы зоналар

1. Шәһәр, авыл һәм башка торак пунктлар чикләрендә (читләрендә) сөрүлекләр, бакчалар, яшелчәчелекләр, печәнлекләр, көтүлекләр, шулай ук авыл хуҗалыгы биналары, төзелмәләре һәм корылмалары урнашкан авыл хуҗалыгы файдалануындагы зоналар бүлеп бирелә.

2. Күрсәтелгән зоналарның территорияләре корылышның генераль планы һәм кагыйдәләре нигезендә авыл хуҗалыгын алып бару максатларында алардан файдалану төре үзгәргәнчегә кадәр файдаланырга мөмкин.

48 статья. Махсус билгеләнештәге зоналар

1. Махсус билгеләнештәге зоналар зиратлар, крематорийлар, терлек зиратлары, көнкүреш калдыклары урыннары һәм шәһәр, авыл торак пунктларының территория зоналарында башка төр файдаланышы булмаган башка объектлар өчен бүлеп бирелә.

2. Махсус билгеләнештәге зоналар территорияләреннән файдалану тәртибе, дәүләт шәһәр төзелеше нормативларының һәм кагыйдәләренең, махсус нормативларның таләпләрен исәпкә алып, корылыш кагыйдәләре белән билгеләнә.

49 статья. Хәрби объектлар зоналары һәм режим территорияләренең башка зоналары

1. Хәрби объектлар зоналары һәм режим территорияләренең башка зоналары үз территорияләренә карата законнар нигезендә махсус режим билгеләнүче объектларны урнаштыру өчен каралган.

2. Күрсәтелгән зоналарның территорияләреннән шәһәр һәм авыл торак пунктлары чикләре (читләре) кысаларында файдалану тәртибе дәүләт шәһәр төзелеше нормативлары һәм кагыйдәләре, махсус нормативлар, корылыш кагыйдәләре нигезендә җирле үзидарә органнары белән килешеп, дәүләт идарәсе органнары тарафыннан билгеләнә.

IX бүлек. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген башкарганда шәһәрләрнең шәһәр яны зоналары территорияләреннән файдалануны җайга салу

50 статья. Шәһәрләрнен шәһәр яны зоналары территорияләре

1. Шәһәрләрнен шәһәр яны территорияләренә шәһәр чигендәге (читендәге) һәм әлеге шәһәр территориясе, аның шәһәр яны зонасына керүче шәһәр, авыл торак пунктлары һәм җирле үзидарәнең башка берәмлекләре территорияләре (торак пунктлары үсеше өчен резерв территориясе) үсеше өчен, сәнәга, коммуналь һәм склад объектларын, инженерия, транспорт инфраструктуралары объектларын, бакчачылык һәм дача кооперативлары объектларын, халыкның ял итү урыннарын урнаштыру өчен, шулай ук авыл хуҗалыгын алып бару һәм яклау, санитар-гигиена функцияләрен башкару өчен билгеләнгән җирләр керә.

2. Шәһәрләрнең шәһәр яны зоналарының чикләрен билгеләү, әлеге Кодекска һәм Татарстан Республикасының җир турындагы законнарына таянып, шәһәр төзелеше документациясе нигезендә гамәлгә ашырыла.

51 статья. Шәһәрләрнең шәһәр яны зоналары территорияләреннән файдалануны җайга салу

1. Шәһәрнең шәһәр яны зоналары территориясеннән файдалану һәм әлеге шәһәрнең шәһәр яны чикләрендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге шундый шәһәрләрдәге халыкның һәм әлеге шәһәрнең шәһәр яны зонасына керүче шәһәр, авыл торак пунктлары һәм җирле үзидарәнең башка берәмлекләре халкының, шәһәр яны административ-территория төзелмәләренең, шулай ук шәһәр яны зонасында урнашкан башка шәһәр төзелеше субъектларының мәнфәгатьләрен исәпкә алып башкарыла.

2. Шәһәрләрнең шәһәр яны зоналары территорияләрен зоналаштыру Татарстан Республикасы территориясе, аның территориясенең өлеше (шул исәптән шәһәр яны зонасы да), район, авыл округы территориясе үсешенең шәһәр төзелешен планлаштыруның территориаль комплекслы схемаларында, шулай ук җир һәм урман төзелеше документациясен исәпкә алып, шәһәрләрнең шәһәр яны зоналары белән бергә әзерләнүче генераль планнарында билгеләнә.

3. Шәһәрләрнең шәһәр яны зоналарында санитар, санитар-гигиена һәм рекреацион функцияләрне үтәүче яшел зоналар билгеләнә. Яшел зоналарда әйләнә-тирә табигать мохитенә зарарлы йогынты ясаучы хуҗалык һәм башка төрле эшчәнлек тыела.

4. Шәһәр яны зонасы читләрендәге торак пунктлар үсеше өчен резерв территорияләр чикләрендә күчемсез объектларны төзү, реконструкцияләү һәм зурайту Татарстан Республикасының дәүләт идарәсе органнары һәм җирле үзидарә органнары белән килешеп башкарыла.

5. Гражданнар һәм юридик затлар милкендәге һәм шәһәр яны зонасы чикләрендә торак пунктлары үсеше өчен резерв территорияләр чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләрен дәүләт ихтыяҗлары һәм җирле үзидарә ихтыяҗлары өчен сатып алу җир турындагы законнар һәм граждан законнары нигезендә башкарыла.

## X бүлек. Дәүләт шәһәр төзелеше нормативлары һәм кагыйдәләре

52 статья. Дәүләт шәһәр төзелеше нормативлары һәм кагыйдәләре

1. Дәүләт шәһәр төзелеше нормативлары һәм кагыйдәләре төзелештә норматив-техник документлар системасының төп өлешен тәшкил итә.

2. Дәүләт шәһәр төзелеше нормативларын һәм кагыйдәләрен дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, дәүләт контроле һәм күзәтчелеге органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыручы гражданнар һәм юридик затлар һичшиксез үтәргә тиеш.

Дәүләт шәһәр төзелеше нормативларын һәм кагыйдәләрен әзерләү, теркәү, раслау, гамәлгә кертү, кабат карау һәм юкка чыгару тәртибе архитектура һәм шәһәр төзелеше органы тарафыннан билгеләнә.

3. Дәүләт шәһәр төзелеше нормативлары һәм кагыйдәләре дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары һәм җирле үзидарә органнары, шәһәр төзелеше өлкәсендә контрольне гамәлгә ашыручы дәүләт органнары, милекчеләрнең, биләүчеләрнең, файдаланучыларның һәм арендаторларның шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге хокуклары, шулай ук, дәүләт шәһәр төзелеше нормативларын һәм кагыйдәләрен бозган очракта, гражданнарның һәм юридик затларның хокуклары мәсьәләләре буенча хокук саклау органнары тарафыннан карарлар чыгару өчен нигез булып тора.

4. Шәһәр, авыл һәм башка торак пунктлар территорияләрендә шәһәр төзелеше эшчәнлеген җайга салу өчен, дәүләт шәһәр төзелеше нормативларына һәм кагыйдәләренә өстәп, корылышның җирле кагыйдәләре дә эшләнә.

<u>53 статья.</u> Татарстан Республикасының шәһәр төзелеше нормативлары һәм кагыйдәләре

1. Татарстан Республикасының шәһәр төзелеше нормативлары һәм кагыйдәләре (алга таба шәһәр төзелешенең территория нормативлары һәм кагыйдәләре) республиканың табигать-климат, социаль-демографик, милли һәм башка үзенчәлекләрен исәпкә алып әзерләнә.

Шәһәр төзелешенең Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнары тарафыннан расланган территория нормативлары һәм кагыйдәләре Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә була һәм шәһәр төзелеше эшчәнлегендә катнашучыларның барысы да аларны һичшиксез үтәргә тиеш.

2. Шәһәр төзелешенең территория нормативлары һәм кагыйдәләре билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана, теркәлү өчен архитектура һәм шәһәр төзелешенең федераль органына җибәрелә һәм матбугатта басылырга тиеш.

XI бүлек. Татарстан Республикасының дәүләт шәһәр төзелеше кадастры һәм шәһәр төзелеше объектлары мониторингы

<u>54 статья.</u> Татарстан Республикасының дәүләт шәһәр төзелеше кадастрын һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектлары мониторингын билгеләү

1. Татарстан Республикасының дәүләт шәһәр төзелеше кадастры - шәһәр төзелеше эшчәнлеген, шул исәптән күчемсез объектларны үзгәртүне гамәлгә ашыру өчен кирәкле белешмәләрнең дәүләт мәгълүмат системасы.

2. Татарстан Республикасының дәүләт шәһәр төзелеше кадастры шәһәр, авыл торак пунктларына һәм башка җирле үзидарә берәмлекләренә, торакара территорияләргә һәм Татарстан Республикасы территориясенә карата алып барыла.

3. Дәүләт шәһәр төзелеше кадастрының нигезен Татарстан Республикасының дәүләт җир кадастры тәшкил итә. Татарстан Республикасының дәүләт шәһәр төзелеше кадастры шулай ук башка тармак кадастрлары белешмәләрен һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка мәгълүмат системаларын үз эченә ала.

4. Татарстан Республикасының дәүләт шәһәр төзелеше кадастры Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы өчен бердәм система буенча алып барыла.

5. Территорияләрнең һәм торак пунктларының үсешен шәһәр төзелеше ягыннан планлаштыру турындагы һәм аларның корылышы турындагы шәһәр төзелеше документлары Татарстан Республикасының дәүләт шәһәр төзелеше кадастры нигезен тәшкил итә.

Татарстан Республикасының дәүләт шәһәр төзелеше кадастры түбәндәгеләрне үз эченә ала:

топографик-геодезик һәм картографик материаллар;

территорияләрнең экологик, инженерия-геологик, сейсмик, гидрологик торышы турындагы белешмәләр;

инженерия, транспорт һәм социаль инфраструктуралар объектлары турындагы һәм территорияләрне төзекләндерү турындагы белешмәләр;

территорияләрнең һәм торак пунктларының үсешен шәһәр төзелеше ягыннан планлаштыру турында һәм аларны кору турында белешмәләр;

территорияләрне зоналаштыру турында һәм территориаль зоналарны шәһәр төзелеше ягыннан регламентлау турында белешмәләр.

6. Шәһәр һәм авыл торак пунктларының шәһәр төзелеше кадастрлары Татарстан Республикасының дәүләт шәһәр төзелеше кадастры өчен мәгълүмати нигез булып тора.

7. Татарстан Республикасының дәүләт шәһәр төзелеше кадастры белешмәләре шәһәр төзелеше һәм проектлау документларын әзерләгәндә һәм гамәлгә ашырганда файдаланыла.

8. Татарстан Республикасының дәүләт шәһәр төзелеше кадастры белешмәләре, дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән гайре, гомуми файдаланылышта була һәм мәгълүмати процесслар, мәгълүматлаштыру һәм мәгълүматларны яклау өлкәсендәге законнар белән билгеләнгән тәртиптә бирелә. Дәүләт шәһәр төзелеше кадастрының дөрес булмаган белешмәләрен бирүдән килгән зыян тиешле мәгълүмат ресурслары биләүчесе тарафыннан түләнә.

9. Шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектлары мониторингы - шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектларының торышын һәм үзгәрешен күзәтү

системасы, ул яшәеш мохите торышын өйрәнү ярдәмендә бердәм методика буенча алып барыла.

Шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектлары мониторингы белешмәләре Татарстан Республикасының дәүләт шәһәр төзелеше кадастрына кертелергә тиеш.

55 статья. Татарстан Республикасының дәүләт шәһәр төзелеше кадастрын һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектлары мониторингын алып бару тәртибе

1. Татарстан Республикасының дәүләт шәһәр төзелеше кадастрын һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектлары мониторингын алып бару республика бюджеты акчалары исәбеннән, шулай ук гражданнарга һәм юридик затларга дәүләт шөһәр төзелеше кадастры белешмәләрен бирү хезмәтләрен күрсәтүдән алынган акчалар исәбеннән республика архитектура һәм шәһәр төзелеше органы тарафыннан башкарыла.

Дәүләт идарәсенең җирле органнары, җирле үзидарә органнары үзләренә тиешле вәкаләтләр бирелгән һәм күрсәтелгән вәкаләтләрне башкару өчен кирәкле финанс һәм матди чаралар тапшырылган очракта шәһәр һәм авыл торак пунктларының тиешле территорияләрендә дәүләт шәһәр кадастры һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектлары мониторингын алып баралар. Җирле бюджет акчалары, шулай ук гражданнарга һәм юридик затларга дәүләт шәһәр төзелеше кадастры белешмәләрен бирү хезмәтләрен күрсәтүдән алынган акчалар дәүләт идарәсенең җирле органнары, җирле үзидарә органнары карары белән тиешле территориядә дәүләт шәһәр кадастры һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектлары мониторингын алып бару өчен файдаланылырга мөмкин.

2. Татарстан Республикасының дәүләт шәһәр төзелеше кадастрын һәм республика территориясендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектлары мониторингын алып бару тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

## XII бүлек. Шәһәр һәм авыл торак пунктлары территорияләре корылышын җайга салу

56 статья. Шөһәр һәм авыл торак пунктларында җир кишәрлекләреннән файдалануга шәһәр төзелеше ягыннан таләпләр

1. Җир кишәрлекләре бирелгәндә алардан файдалануга шәһәр төзелеше ягыннан таләпләр шәһәр һәм авыл торак пунктларының генераль планнары, планлаштыру һәм төзелеш проектлары, шулай ук төзелеш буенча җирле кагыйдәләр белән билгеләнә.

Җир кишәрлекләре бирелгәндә шәһәрләрнең һәм районнарның җирле дминистрацияләре, җирле үзидарә органнары җир кишәрлекләреннән айдалануга шәһәр төзелеше ягыннан таләпләр турында түбәндәге әгълүматны әзерли:

җир кишәрлекләренең урнашу урыны;

планлаштыру проектлары, төзелеш проектлары һәм территорияләрне ызанлау проектлары нигезендә җир кишәрлекләре чикләре проектлары;

җир кишәрлекләреннән рөхсәтле файдалану;

җир кишәрлекләрен инженерия, транспорт һәм социаль нфраструктуралар объектлары белән тәэмин итү.

Шәһәрләрнец һәм районнарның җирле администрацияләре, җирле зидарә органнары җир кишәрлекләре бирелгәндә алардан файдалануга арата әлеге статьяның 4 пунктында каралган өстәмә таләпләрне билгели лалар.

2. Шәһәр һәм авыл торак пунктларында күчемсез объектларны өзегәндә күчемсез объектларны урнаштыруны төзелеш һәм шәһәр төзелеше егламентлары турындагы билгеләнгән тәртиптә расланган шәһәр төзелеше окументлары нигезендә алдан килештерү уткәрелми.

3. Шәһәр һәм авыл торак пунктларында җир кишәрлекләре бирү атарстан Республикасының җир турындагы законнары нигезендә гамәлгә шырыла.

Җир кишәрлекләрен милек, файдалану яисә озак вакытлы арендалау окукында биргән очракта шәһәрләрнең һәм районнарның җирле дминистрацияләре, җирле үзидарә органнары конкурслар яисә аукционнар гълан итәргә хокуклы (моңа законнарда каралган очраклар керми).

4. Кору өчен җир кишәрлекләрен гражданнарга һәм юридик затларга ату буенча конкурслар уткәргәндә, анда катнашучыларга түбәндәге өстәмә аләпләр билгеләнергә мөмкин:

күчемсез объектларны сүтүдән, анда яшәүчеләрне күчерүдән, ранспорт, элемтә һәм инженерия җиһазлары корылмаларын һәм оммуникацияләрен күчерүдән килгән зыянны һәм башка чыгымнарны үләү;

инженерия, транспорт һәм социаль инфраструктура объектларын төзү;

күчемсез объектларны төзү вакытларын үтәү;

гомуми файдаланылыштагы территорияләрне төзекләндерү.

Күрсәтелгән таләпләр җир кишәрлегенә хокуклар башка затка үчкәндә дә саклана.

5. Җир кишәрлеген милек, файдалану яисә озак вакытка арендалау окукында алган коручы аны кору проектын яисә билгеләнгән тәртиптә башка затка кору өчен әзерләнгән яисә корылган җир кишәрлеген тапшыру буенча аны ызанлау проектын әзерләргә һәм гамәлгә ашырырга хокуклы.

6. Шәһәр һәм авыл торак пунктларында җир кишәрлегенә хокукны раслаучы документка мәҗбүри төстә түбәндәге мәгълүмат кертелергә тиеш:

йортлар төзү кагыйдәләре белән билгеләнгән территориаль зона коды;

җир кишәрлеге аның чикләрендә урнашкан территориаль зонаның функциональ билгеләнеше;

җир кишәрлекләренең яисә аларның өлешләренең тарих һәм мәдәният ядкярләрен саклау, махсус сакланылучы табигый территорияләр зоналары, сусаклагыч зоналар чикләрендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш вәзгыятьләрнең йогынтысына дучар булган территорияләр һәм файдаланылышы Татарстан Республикасы законнары белән чикләнгән башка территорияләр чикләрендә урнашуы;

параметрларын һәм күрсәтелгән объектлардан файдалануда чикләүләрне күрсәтеп,җир кишәрлеге чикләрендә дәүләт милкендәге инженерия, транспорт һәм социаль инфраструктура объектлары булу;

күрсәтелгән объектлар урнашуга бәйле рәвештә әлеге җир кишәрлегеннән файдалануда чикләүләрне күрсәтеп, әлеге җир кишәрлеге милекчесенә, аны биләүчегә, аннан файдаланучыга яисә арендалаучыга карамаган биналар, төзелмәләр һәм корылмалар булу.

7. Җир кишәрлекләрен бүлгәндә яисә аларның чикләрен һәм параметрларын үзгәрткәндә кызыл линияләр, җир кишәрлекләренең минималь үлчәмнәренә шәһәр төзелеше регламентлары таләпләре һәм коруны җайга салу линияләре саклана.

Күчемсез объектларны бүлгән очракта аларның өлешләренең мөстәкыйль күчемсез объектлар буларак функцияләве өчен шартлар тәэмин ителергә тиеш.

<u>57 статья.</u> Шәһәр һәм авыл торак пунктлары территорияләрендә йортлар кору турында шәһәр төзелеше документациясе

Шәһәр һәм авыл торак пунктлары территорияләрендә йортлар кору турында шәһәр төзелеше документлары (әлеге Кодексның 31 статьясындагы 3 пункт) шәһәр һәм авыл торак пунктлары территорияләре үсешен шәһәр төзелеше ягыннан планлаштыру турында шәһәр төзелеше документлары һәм йортлар кору кагыйдәләре нигезендә йортлар коручылар, дәүләт идарәсенең җирле органнары яисә җирле үзидарә органнары заказы буенча аларның акчалары исәбеннән эшләнә.

<u>58 статья.</u> Планлаштыру проектлары

1. Планлаштыру проектлары - шәһәр һәм авыл торак пунктлары территорияләренең өлешләре өчен эшләнгән һәм шәһәр һәм авыл торак пунктларының генераль планнарында планлаштыру структурасы элементлары нигезендә түбәндәгеләрне билгеләүче шәһәр төзелеше документлары:

кызыл линияләр һәм коруны җайга салу линияләре;

жир кишәрлекләре чикләре (планлаштыру проектлары составында территорияләрне ызанлау проектларын эшләгәндә);

халыкка социаль һәм мәдәни-көнкүреш хезмәте күрсәтү объектларын урнаштыру;

коруның тыгызлыгы һәм параметрлары;

урамнарның, үтү юлларының, җәяүлеләр йөри торган зоналарның, шулай ук корылмаларның һәм транспорт, элемтә, инженерия җиһазлары коммуникацияләренең һәм территорияләрне төзекләндерү параметрлары.

Планлаштыру проектына кору һәм территорияне төзекләндерү эскизы керергә мөмкин.

2. Планлаштыру проекты матбугатта бастырып чыгарылырга, халык тарафыннан тикшерелергә тиеш һәм ул, шул тикшерү нәтиҗәләрен исәпкә алып, дәүләт идарәсенең җирле органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан раслана.

3. Планлаштыру проекты территорияләрне ызанлау проектларын, кварталларны, микрорайоннарны һәм шәһәр, авыл торак пунктларының башка планлаштыру структурасы элементларын кору проектларын эшләү өчен нигез булып тора.

<u>59 статья.</u> Территорияләрне ызанлау проектлары

1. Төзелгән территорияләр һәм кызыл линияләр белән билгеләнгән чикләрдә корылырга тиешле территорияләр өчен территорияләрне ызанлау проектлары эшләнә.

2. Территорияләрне ызанлау проектлары шәһәр һәм авыл торак пунктлары территорияләре өлешләрен ызанлау проектлары, кварталларны, микрорайоннарны кору һәм шәһәр, авыл торак пунктларының башка планлаштыру структурасы элементлары проектлары составында эшләнергә мөмкин.

3. Шәһәр һәм авыл торак пунктларының корылган территорияләре чикләрендә гомуми файдаланудагы территорияләрне ызанлау үткәрелми.

4. Шәһәр һәм авыл торак пунктларының корылган территорияләре чикләрендә җир кишәрлекләре үлчәмнәре әлеге территорияләрне корган чорда фактта җирдән файдалану һәм шәһәр төзелеше буенча гамәлдә булган нормативларны исәпкә алып билгеләнә.

Әгәр территорияләрне ызанлау барышында шәһәр төзелешенең билгеләнгән нормативларыннан артып киткән үлчәмдәге территорияләр барлыгы ачыкланса, андый территорияләр, барлыкка килгән җир кишәрлеге шәһәр төзелеше регламентына туры килгәндә, күчемсез объектлар төзү өчен бүлеп бирелә.

5. Яңа үзләштерелүче территорияләрдә җир кишәрлекләрен бирү нормалары дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, шулай ук җирле үзидарә органнары тарафыннан кору кагыйдәләре нигезендә билгеләнә.

6. Җир кишәрлекләренең элек билгеләнгән чикләре үзгәргән очракта мондый җир кишәрлекләрен дәүләт ихтыяҗлары өчен тартып алу яисә сатып алу Татарстан Республикасының җир турындагы законнары һәм граждан законнары нигезендә башкарыла.

7. Территорияләрне ызанлау проектлары дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан раслана һәм урыннарда җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү өчен нигез булып тора.

8. Территорияләрне ызанлау проектларын эшләү һәм раслау тәртибе дәүләт идарәсенең җирле органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.

<u>60 статья.</u> Кору проектлары

1. Кору проектлары билгеләнгән кызыл линияләр чикләрендә яисә җир кишәрлекләре чикләрендә шәһәр һәм авыл торак пунктлары кварталлары, микрорайоннары һәм башка планлаштыру структурасы элементлары территорияләре өчен эшләнә. Җир кишәрлегендә төзелеш проекты йорт төзү инициативасы буенча эшләнергә мөмкин.

2. Җир кишәрлеген, шәһәр, авыл торак пунктлары кварталларын, микрорайоннарын һәм башка планлаштыру структурасы элементларын кору проектларында түбәндәгеләр билгеләнә:

коруны җайга салу линияләре;

биналарның, корылмаларның һәм төзелмәләрнең урнашуы,ничә катлы булуы, төре һәм башка характеристикалары;

коруның архитектура чишелеше;

инженерия җиһазлары, элемтә һәм төзекләндерү системалары, шулай үк әлеге системаларны җир кишәрлекләреннән, кварталлардан, микрорайоннардан һәм шәһәр, авыл торак пунктларының башка планлаштыру структурасы элементларыннан читтә урнашкан инженерия җиһазлары, элемтә һәм төзекләндерү системалары корылмаларына һәм коммуникацияләренә кушу шартлары;

транспорт чараларының һәм җәяүлеләрнең хәрәкәтен оештыру;

гомуми файдаланыштагы территорияләр.

3. Дәүләт идарәсенең җирле органнары, җирле үзидарә органнары кору проектларына карата җирле шартлар нигезендә өстәмә таләпләр, шул исәптән тарих һәм мәдәният ядкярләрен саклау зоналарында проектлауга һәм төзелешкә, территорияләрне яшелләндерүгә, кече формадагы архитектура объектларын, рекламаны, элмә такталар һәм күз күремендәге башка мәгълүматлар урнаштыруга таләпләр кертергә хокуклы.

4. Дәүләт идарәсенең җирле органнары, җирле үзидарә органнары заказы буенча эшләнгән кору проектлары әлеге органнар тарафыннан халык фикерен исәпкә алып законнар билгеләгән тәртиптә раслана.

Заказчылары физик һәм юридик затлар булган төзелеш проектлары законнарда билгеләнгән тәртиптә килештерелә һәм заказчылар тарафыннан раслана.

61 статья. Проектлау документлары

1. Биналарны, төзелмәләрне һәм корылмаларны, аларның өлешләрен төзү, реконструкцияләү һәм аларны капиталь ремонтлау, әлеге объектларны төзү, реконструкцияләү һәм аларны капиталь ремонтлау, шулай ук җир кишәрлекләрен төзекләндерү өчен күләм-планлаштыру, конструктив һәм техник хәл ителешне билгеләүче график һәм текстлы материаллар - проектлау документлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Проектлау документлары шәһәр төзелеше документлары, төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре нигезендә эшләнә, архитектура һәм шәһәр төзелешенең тиешле органнары, дәүләт контроле һәм күзәтчелеге органнары белән законнар нигезендә килештерелә.

3. Проектлау документларын эшләү, финанслау, раслау һәм аннан файдалану тәртибен билгеләү, аңа үзгәрешләр кертү, билгеләнгән тәртиптә заказчы инициативасы буенча аның исәбеннән башкарыла.

4. Заказчысы булып дәүләт идарәсенең җирле органнары, җирле үзидарә органнары торган проектлау документлары билгеләнгән тәртиптә әлеге органнар тарафыннан раслана.

Заказчысы булып физик һәм юридик затлар торган проектлау документлары билгеләнгән тәртиптә заказчы тарафыннан раслана.

5. Билгеләнгән тәртиптә расланган проектлау документлары төзелешкә рөхсәт бирү өчен нигез булып тора.

62 статья. Төзелешкә рөхсәт

1. Төзелешкә рөхсәт - күчемсез объект милекчесенең, аны биләүченең, арендалаучының яисә аннан файдаланучының җир кишәрлегендә кору, бинаны, төзелмәне һәм корылманы төзү, реконструкцияләү, территорияне төзекләндерү хокукын раслаучы документ.

2. Төзелешкә рөхсәт кызыксынучы физик һәм юридик затларның гаризалары, аларның җир кишәрлекләренә хокукларын таныклаучы документлары нигезендә һәм расланган проектлау документлары булганда әлеге Кодекска таянып бирелә.

Республика әһәмиятендәге күчемсез объектлар төзүгә рөхсәт әлеге Кодекста каралган шартларны үтәгән килеш бирелә.

Төзелешкә рөхсәт бирү өчен документларны архитектура һәм шәһәр төзелеше буенча тиешле органнар әзерли.

3. Төзелешкә рөхсәт бирү турындагы гаризаның формасы, әлеге гаризаны карау тәртибе һәм вакытлары, каралырга тәкъдим ителгән

материалларның исемлеге, төзелешкә рөхсәтнең формасы, әлеге рөхсәтне гамәлгә кертү тәртибе һәм аның гамәлдә булу чоры, шулай ук төзелешкә рөхсәт бирүдән баш тартуга шикаять белдерү тәртибе әлеге Кодекс, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

4. Төзелешкә рөхсәт һәм расланган проектлау документлары дәүләт идарәсе органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан теркәлергә тиеш.

5. Төзелешкә рөхсәт булу турындагы мәгълүмат заказчы тарафыннан гражданнарга һәм юридик затларга әлеге төр визуаль мәгълүматка карата архитектура һәм шәһәр төзелеше органнары билгеләгән таләпләр нигезендә, бирелә. Заказчы төзелеш башлану вакыты турындагы мәгълүматны архитектура һәм шәһәр төзелеше тиешле органнарына бирергә тиеш.

6. Дәүләт идарәсе органнары, җирле үзидарә органнары түбәндәге очракларда төзелешкә рөхсәт бирүдән баш тарта алалар:

проектлау документлары җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалануга туры килмәгәндә;

проектлау документлары төзелеш нормаларына һәм кагыйдәләренә туры килмәгәндә.

7. Төзелешкә рөхсәт бирү яисә аннан баш тарту турындагы карарга карата судта шикаять белдерелергә мөмкин.

8. Төзелешкә рөхсәт өч елдан да артык булмаган вакытка бирелә.

Төзелешкә рөхсәт заказчы гаризасы нигезендә озайтылырга мөмкин. Төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булуын озайту тәртибе һәм вакыты дәүләт идарәсенең җирле органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.

9. Күчемсез объектларны төзү һәм реконструкцияләү эшләре биналарның, төзелмәләрнең һәм корылмаларның конструктив һәм башка ышанычлылык һәм иминлек характеристикасына кагылмаганда, шулай ук төзү эшләрен оештыру өчен кирәкле вакытлы биналар, төзелмәләр һәм корылмалар торгызу очракларында төзелешкә рөхсәт таләп ителми.

10. Төзүгә рөхсәт таләп ителми торган күчемсез объектлар төзү һәм реконструкцияләү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан өстәмә исемлек билгеләнергә мөмкин.

11. Күчемсез объектларга милек хокуклары күчкәндә, аларны төзүгә рөхсәт гамәлдә кала. Әлеге төзелешкә рөхсәт кабат теркәлергә тиеш.

12. Төзелешкә рөхсәт, шулай ук шәһәр төзелеше регламентлары, төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре нигезендә күчемсез объектлар төзү һәм реконструкцияләү буенча эшләр башкаруны тикшереп тору Татарстан Республикасының архитектура һәм шәһәр төзелеше буенча тиешле органнарына һәм архитектура-төзелеш дәүләт күзәтчелек органнарына йөкләнә.

63 статья. Махсус рөхсәтләр

Дәүләт серен тәшкил итүче күчемсез объектларны төзүгә рөхсәтләр, дәүләт сере турындагы законнар нигезендә, дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдаланып, эшләрне үткәрүгә лицензияләр нигезендә бирелә.

64 статья. Шәһәр төзелеше өлкәсендә сервитутлар

1. Шәһәр төзелешендә күчемсез объектларга карата ачык һәм хосусый сервитутлар билгеләнергә мөмкин.

2. Ачык сервитут, ул дәүләт яисә җәмәгать мәнфәгатьләре белән билгеләнгән очракларда, дәүләт идарәсе җирле органнарының, җирле үзидарә органнарының хокукый актлары белән шәһәр төзелеше документлары һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә билгеләнә.

3. Шәһәр төзелеше өлкәсендә хосусый сервитутлар чит (күрше) жир кишәрлегеннән, башка күчемсез объектлардан файдалануны чикләү максатларында түбәндәгеләрне тәэмин итү өчен билгеләнергә мөмкин:

биналарны, корылмаларны һәм төзелмәләрне төзү, реконструкцияләү, ремонтлау;

инженерия һәм транспорт инфраструктурасы объектларын төзү, реконструкцияләү, ремонтлау һәм эксплуатацияләү;

территорияләрне инженерия әзерләве эшләрен, территорияләрне су басудан саклау, ныгытылган стеналар төзү эшләрен башкару;

чит (күрше) жир кишәрлеге аша үтү, транспортка утырып узу;

биналар, төзелмәләр һәм корылмалар төзегәндә чит (күрше) жир кишәрлегенә кирәклек билгеле бер биеклектәге жайланмаларны куллану;

блокировкаланган кору йортларында уртак конструктив элементлардан һәм инженерия жиһазларыннан файдалану һәм аларны ремонтлау;

күчемсез объектлар милекчеләренең сервитут билгеләнмәгән килеш тәэмин ителми торган бүтән ихтыяжлары.

4. Сервитутларны билгеләү һәм туктату граждани законнар нигезендә билгеләнә.

## XIII бүлек. Шәһәр төзелешен гамәлгә ашыруга контроль һәм Татарстан Республикасының шәһәр төзелеше турындагы законнарын бозган өчен җаваплылык

65 статья. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыруга контроль

1. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыруга контроль шәһәр төзелеше документлары, дәүләт шәһәр төзелеше нормативлары һәм

кагыйдәләре, кору кагыйдәләре нигезендә шәһәр төзелеше өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

2. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыруга контроль үз компетенцияләре чикләрендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, дәүләт идарәсенең җирле органнары, җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасының архитектура һәм шәһәр төзелеше органнары тарафыннан башкарыла.

3. Архитектура һәм шәһәр төзелеше органнарының урындагы затлары үз вәкаләтләре чикләрендә түбәндәгеләргә хокуклы:

шәһәр төзелеше эшчәнлеге субъектлары тарафыннан шәһәр төзелеше һәм проект документлары, дәүләт шәһәр төзелеше нормативлары һәм кагыйдәләре, төзелешкә рөхсәт таләпләрен үтәү турында мәгълүмат алу максатларында күчемсез объектларны төзүгә, реконструкцияләүгә, ремонтлауга контроль уздырырга;

шәһәр төзелеше турындагы законнарны бозуда гаепле затларны билгеләнгән тәртиптә административ җаваплылыкка тартырга;

шәһәр төзелеше турындагы законнарны бозуда гаепле затларны дисциплинар, административ яисә җинаять җаваплылыгына тарту өчен материаллар җибәрергә;

әгәр шәһәр төзелеше эшчәнлеге шәһәр төзелеше турындагы законнарны бозып гамәлгә ашырылса, тормыш эшчәнлеге мохитенә китерелгән зыянны түләттерү турында судка дәгъва белдерергә;

шәһәр төзелеше турындагы законнарны бозып гамәлгә ашырылучы шәһәр төзелеше эшчәнлеген туктатып тору яисә туктату турында карарлар кабул итәргә.

Шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыруга контрольне башкаручы күрсәтелгән урындагы затларның гамәлләренә һәм карарларына судта билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерелергә мөмкин.

4. Архитектура һәм шәһәр төзелеше республика органы, архитектура һәм шәһәр төзелеше җирле органнары шәһәр һәм авыл торак пунктлары үсешен һәм аларны коруны шәһәр төзелеше ягыннан планлаштыру турындагы шәһәр төзелеше документлары, шулай ук дәүләт шәһәр төзелеше нормативлары һәм кагыйдәләре таләпләренең шәһәр һәм авыл торак пунктларында җирләрдән файдаланганда һәм аларны саклаганда үтәлешенә дәүләт контролен гамәлгә ашыра.

5. Татарстан Республикасы законнары һәм бүтән норматив хокукый актлары, җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары нигезендә архитектура һәм шәһәр төзелешенең тиешле органнарына шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыруга контроль үткәрү буенча өстәмә вәкаләтләр бирелергә мөмкин.

66 статья. Шәһәр төзелеше турындагы законнарны бозган өчен җаваплылык

1. Шәһәр төзелеше турындагы законнарны бозган өчен Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә дисциплинар, административ, җинаять җаваплылыгы һәм башка җаваплылык билгеләнә.

2. Шәһәр төзелеше турындагы законнарны бозган өчен штрафлар үз компетенцияләре чикләрендә архитектура һәм шәһәр төзелеше органнарының урындагы затлары яисә архитектура һәм шәһәр төзелешенең тиешле органнары тарафыннан төзелгән комиссияләр, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең вәкаләтле органнары йә җирле үзидарә органнары тарафыннан салына.

Шәһәр төзелеше өлкәсендә административ хокук бозулар турындагы эшләрне карарга вәкаләтле органнарның (урындагы затларның) компетенцияләрен чикләү законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

3. Әлеге Кодекста күрсәтелгән хокук бозулар өчен гражданнардан, урындагы затлардан һәм юридик затлардан кергән штрафлар штраф салу турында карар кабул иткән орган яисә урындагы зат урнашкан җирле бюджетларга күчерелә.

4. Шәһәр төзелеше турындагы законнарны бозган өчен җинаять җаваплылыгы федераль закон белән билгеләнелә.

67 статья. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген шәһәр төзелеше турындагы законнарны бозып гамәлгә ашырганда тормыш эшчәнлеге мохитенә китергән зыянны түләттерү

Шәһәр төзелеше эшчәнлеген шәһәр төзелеше турындагы законнарны бозып гамәлгә ашырганда тормыш эшчәнлеге мохитенә зыян китергән гражданнар һәм юридик затлар үзләре китергән зыянны граждан законнарында билгеләнгән күләмдә һәм тәртиптә түләргә тиешләр.

XIV бүлек. Шәһәр төзелеше эшчәнлегенең икътисадый нигезе

68 статья. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген финанслау чыганаклары

Шәһәр төзелеше эшчәнлеге түбәндәгеләр исәбеннән финанслана:

җирле бюджетлар акчалары, шул исәптән шәһәр һәм авыл торак пунктлары территорияләрен социаль һәм инженерия ягыннан төзү җирләре өчен түләүдән алынган акчалар;

заказчылар, инвесторлар акчалары;

дәүләт учреждениеләренең һәм дәүләт унитар предприятиеләренең үзәкләштерелгән акчалары;

дәүләт учреждениеләренең һәм дәүләт унитар предприятиеләренең үзәкләштерелгән акчалары;

федераль бюджеттан федераль максатчыл программаларны, социаль-икътисадый үсеш программаларын гамәлгә ашыру өчен бирелгән акчалар;

Татарстан Республикасы республика бюджеты акчалары;

шәһәр төзелеше документларын эшләүгә, шәһәр төзелеше өлкәсендә фәнни-тикшеренү эшләре алып баруга, шул исәптән милек рәвешләренә һәм финанслау чыганакларына бәйсез рәвештә гамәлгә кертелүче күчемсез объектлар хакыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән күләмнәрдә түләүләр исәбеннән, максатчыл һәм бюджеттан тыш фондлар акчалары;

инженерия, транспорт һәм социаль инфраструктураларны үстерүдә өлешләп катнашу исәбеннән гражданнардан һәм юридик затлардан кергән акчалар;

дәүләт һәм коммуналь предприятиеләрне хосусыйлаштырудан кергән акчалар;

билгеләнгән тәртиптә рөхсәт ителгән эшчәнлектән һәм архитектура һәм шәһәр төзелешенең тиешле органнары күрсәтелә торган хезмәтләрдән кергән акчалар;

законнар белән тыелмаган башка чыганаклар.

<u>69 статья.</u> Татарстан Республикасының республика бюджеты акчаларыннан шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыруда файдалану

Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыруда түбәндәгеләрне финанслау өчен файдаланыла:

республика дәрәҗәсендәге шәһәр төзелеше документларын эшләү;

республика законнары һәм бүтән норматив хокукый актлар проектларын, республика шәһәр төзелеше нормативларын һәм кагыйдәләрен эшләү;

шәһәр төзелешенең иң мөһим юнәлешләре буенча фәнни-тикшеренү эшләре алып бару;

депрессив районнар, гадәттән тыш экологик хәлләр һәм экологик бәла-казалар зоналары, республика әһәмиятендәге тарихи торак пунктлар, инженерия, транспорт, социаль инфраструктуралар үсешенең республика максатчыл программаларын, республиканың башка максатчыл программаларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, шулай ук дәүләт шәһәр төзелеше кадастрын алып бару.

70 статья. Шәһәр төзелеше турында Татарстан Республикасы законнарын бозу нәтиҗәсендә һәм шуның аркасында тормыш эшчәнлеге мохите үзгәреп гражданнарга китерелгән зыянны административ тәртиптә компенсацияләү

1. Шәһәр төзелеше турында законнарны бозу нәтиҗәсендә һәм шуның аркасында тормыш эшчәнлеге мохитен начарайтып гражданнарга зыян китерелгән очракта Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнары, дәүләт идарәсенең җирле органнары, җирле үзидарә органнары китерелгән зыянны компенсацияләү турында, шул исәптән махсус өстенлекле ташламалар һәм пособиеләр билгеләү турында карарлар кабул итәргә мөмкин.

2. Махсус өстенлекле ташламалар һәм пособиеләр зыян күргән гражданнарның аерым категорияләре өчен билгеләнә. Махсус өстенлекле ташламалар һәм пособиеләр билгеләнгән зыян күргән гражданнарның категорияләре дәүләт идарәсенең тиешле органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.

3. Махсус өстенлекле ташламалар беренче чиратта яисә чираттан тыш торак биналар бирелү рәвешендә дә билгеләнергә мөмкин. Махсус пособиеләр гражданнарны күчереп урнаштыру һәм аларның яңа торак урыннарын минималь яшәрлек итү өчен дә түләнергә мөмкин.

4. Зыян күргән гражданнарның аерым категорияләре өчен махсус ташламалар бирүгә һәм пособиеләргә акчалар тиешле бюджетлар һәм закон белән тыелмаган башка чыганаклар исәбеннән түләнә.

5. Шәһәр төзелеше турындагы законнарны бозу нәтиҗәсендә китерелгән һәм шуның аркасында тормыш эшчәнлеге мохитен начарайтып гражданнарга китерелгән зыянны махсус өстенлекле ташламалар һәм пособиеләр билгеләү белән компенсацияләү шәһәр төзелеше турында законнарны бозуда гаепле затларны алар китергән зыянны түләүдән азат итми.

## XV бүлек. Шәһәр төзелеше өлкәсендә халыкара хезмәттәшлек

71 статья. Шәһәр төзелеше өлкәсендә халыкара хезмәттәшлек

Шәһәр төзелеше өлкәсендә Татарстан Республикасының халыкара хезмәттәшлеге законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

## XVI бүлек. Йомгаклау нигезләмәләре

72 статья. Әлеге Кодексны гамәлгә кертү турында

1. Әлеге Кодексны рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасының шәһәр төзелеше өлкәсендәге законнары һәм бүтән норматив хокукый актлары әлеге Кодекска каршы килмәгәндә генә кулланыла.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үз норматив хокукый актларын әлеге Кодекска туры китерүне йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 22 феврале
№ 643